– Иван Фёдорович Денисовның тууына 100 ел (19.12.1924–1995)

**110** лет со дня рождения Гаврила Петровича Евсеева (15.07.1914–1973)

– Гаврил Петрович Евсеевның тууына 110 ел (15.07.1914–1973)

**125** лет со дня рождения Михаила Григорьевича Елисеева (07.11.1899–1943)

– Михаил Григорьевич Елисеевның тууына 120 ел (07.11.1899–1943)

**110** лет со дня рождения Бориса (Барый) Мусеевича Еналиева (15.06.1914–1982)

– Борис (Барый) Муса улы Еналиевның тууына 110 ел (15.06.1914–1982)

**100** лет со дня рождения Михаила Романовича Иванова (03.01.1924–1965)

– Михаил Романович Ивановның тууына 100 ел (03.01.1924–1965)

**120** лет со дня рождения Николая Петровича Иванова (15.11.1904–1959)

– Николай Петрович Ивановның тууына 120 ел (15.11.1904–1959)

**110** лет со дня рождения Андрея Фёдоровича Иванченко (15.07.1914–1945)

– Андрей Фёдорович Иванченконың тууына 110 ел (15.07.1914–1945)

**110** лет со дня рождения Дмитрия Даниловича Ивлева (29.10.1914–1998)

– Дмитрий Данилович Ивлевның тууына 110 ел (29.10.1914–1998)

**100** лет со дня рождения Виктора Владимировича Истомина (12.01.1924–2000)

– Виктор Владимирович Истоминның тууына 100 ел (12.01.1924–2000)

**110** лет со дня рождения Фараха Гимдеевича Камалдинова (25.05.1914–1989, по другим данным – 1984)

– Фәррах Гимдәй улы Камалетдиновның тууына 110 ел (25.05.1914–1989, башка мәгълүматлар буенча 1984)

**110** лет со дня рождения Салавата Хакимовича Каримова (15.09.1914–1986)

– Салават Хәким улы Кәримовның тууына 110 ел (15.09.1914–1986)

**100** лет со дня рождения Николая Яковлевича Касаткина (23.12.1924–1945)

– Николай Яковлевич Касаткинның тууына 100 ел (23.12.1924–1945)

**100** лет со дня рождения Николая Андреевича Катина (21.11.1924–1945)

– Николай Андреевич Катинның тууына 100 ел (21.11.1924–1945)

**120** лет со дня рождения Ермолая Григорьевича Коберидзе (15.04.1904–1974)

– Ермолай Григорьевич Коберидзеның тууына 120 ел (15.04.1904–1974)

**125** лет со дня рождения Ивана Никитича Конева (05.01.1899–1983)

– Иван Никитич Коневның тууына 125 ел (05.01.1899–1983)

**110** лет со дня рождения Ивана Алексеевича Кормилкина (21.01.1914–1989)

– Иван Алексеевич Кормилкинның тууына 110 ел (21.01.1914–1989)

**125** лет со дня рождения Андрея Григорьевича Кравченко (30.11.1899–1963)

– Андрей Григорьевич Кравченконың тууына 125 ел (30.11.1899–1963)

**125** лет со дня рождения Семёна Моисеевича Кривошеина (28.11.1899–1978)

– Семён Моисеевич Кривошеинның тууына 125 ел (28.11.1899–1978)

**110** лет со дня рождения Идриса Моисеевича Кудашева (23.09.1914–1970)

– Идрис Моисей улы Кудашевның тууына 110 ел (23.09.1914–1970)

**110** лет со дня рождения Анатолия Ивановича Кузнецова (27.02.1914–1943)

– Анатолий Иванович Кузнецовның тууына 110 ел (27.02.1914–1943)

**130** лет со дня рождения Василия Ивановича Кузнецова (15.01.1894–1964)

– Василий Иванович Кузнецовның тууына 130 ел (15.01.1894–1964)

**100** лет со дня рождения Ивана Тихоновича Максимова (05.08.1924–1987)

– Иван Тихонович Максимовның тууына 100 ел (05.08.1924–1987)

**100** лет со дня рождения Вячеслава Александровича Медноногова (07.01.1924–1997)

– Вячеслав Александрович Медноноговның тууына 100 ел (07.01.1924–1997)

**110** лет со дня рождения Нурлы Миниахметовича Миниахметова (15.06.1914–1989)

– Нурлы Миңнеәхмәт улы Миңнеәхмәтовның тууына 110 ел (15.06.1914–1989)

**100** лет со дня рождения Петра Ивановича Морозова (01.07.1924–1952)

– Пётр Иванович Морозовның тууына 100 ел (01.07.1924–1952)

**110** лет со дня рождения Григория Фёдоровича Мусланова (25.01.1914–1998)

– Григорий Фёдорович Муслановның тууына 110 ел (25.01.1914–1998)

**100** лет со дня рождения Зайнуллы Мустакимовича Мустакимова (1924–1945)

– Зәйнулла Мөстәкыйм улы Мөстәкыймовның тууына 100 ел (1924–1945)

**120** лет со дня рождения Хамита Ахметовича Неатбакова (1904–1944)

– Хәмит Әхмәт улы Ниятбәков (Неатбәков)ның тууына 120 ел (1904–1944)

**110** лет со дня рождения Владимира Степановича Палагина (20.09.1914–1995)

– Владимир Степанович Палагинның тууына 110 ел (20.09.1914–1995)

**125** лет со дня рождения Алексея Павловича Панфилова (17.05.1899–1966)

– Алексей Павлович Панфиловның тууына 125 ел (17.05.1899–1966)

**100** лет со дня рождения Валентина Дмитриевича Паширова (06.08.1924–1943)

– Валентин Дмитриевич Пашировның тууына 100 ел (06.08.1924–1943)

**120** лет со дня рождения Михаила Петровича Петрова (17.11.1904–1967)

– Михаил Петрович Петровның тууына 120 ел (17.11.1904–1967)

**110** лет со дня рождения Игнатия Павловича Петухова (27.12.1914–1950)

– Игнатий Павлович Петуховның тууына 110 ел (27.12.1914–1950)

**100** лет со дня рождения Петра Алексеевича Полушкина (14.07.1924–2009)

– Пётр Алексеевич Полушкинның тууына 100 ел (14.07.1924–2009)

**120** лет со дня рождения Климента Сергеевича Русакова (04.02.1904–1996)

– Климент Сергеевич Русаковның тууына 120 ел (04.02.1904–1996)

**130** лет со дня рождения Павла Семёновича Рыбалко (04.11.1894–1948)

– Павел Семёнович Рыбалконың тууына 130 ел (04.11.1894–1948)

**100** лет со дня рождения Габдулхая Саитовича Саитова (03.04.1924–2000)

– Габделхәй Сәет улы Сәетовның тууына 100 ел (03.04.1924–2000)

**100** лет со дня рождения Гатауллы Салиховича Салихова (01.01.1924–2012)

– Гатаулла Салих улы Салиховның тууына 100 ел (01.01.1924–2012)

**110** лет со дня рождения Анатолия Васильевича Самочкина (01.05.1914–1977)

– Анатолий Васильевич Самочкинның тууына 110 ел (01.05.1914–1977)

**100** лет со дня рождения Михаила Егоровича Сергеева (28.01.1924–1991)

– Михаил Егорович Сергеевның тууына 100 ел (28.01.1924–1991)

**100** лет со дня рождения Николая Кузьмича Синдрякова (01.01.1924–1943)

– Николай Кузьмич Синдряковның тууына 100 ел (01.01.1924–1943)

**120** лет со дня рождения Николая Леонтьевича Соболева (19.12.1904–1957)

– Николай Леонтьевич Соболевның тууына 120 ел (19.12.1904–1957)

**120** лет со дня рождения Степана Петровича Спирькова (27.12.1904–1982)

– Степан Петрович Спирьковның тууына 120 ел (27.12.1904–1982)

**120** лет со дня рождения Якова Петровича Староверова (21.03.1904–1955)

– Яков Петрович Староверовның тууына 120 ел (21.03.1904–1955)

**125** лет со дня рождения Владимира Филипповича Стенина (10.06.1899–1952)

– Владимир Филиппович Стенинның тууына 125 ел (10.06.1899–1952)

**100** лет со дня рождения Семёна Артемьевича Уганина (07.01.1924–1959)

– Семён Артемьевич Уганинның тууына 100 ел (07.01.1924–1959)

**110** лет со дня рождения Ивана Михайловича Ульянова (22.01.1914–1986)

– Иван Михайлович Ульяновның тууына 110 ел (22.01.1914–1986)

**120** лет со дня рождения Жиганши Закировича Файзуллина (11.03.1904–1985)

– Җиһанша Закир улы Фәйзуллинның тууына 120 ел (11.03.1904–1985)

**110** лет со дня рождения Фарита Мухаметзяновича Фаткуллина (17.03.1914–1942)

– Фәрит Мөхәммәтҗан улы Фәтхуллинның тууына 110 ел (17.03.1914–1942)

**100** лет со дня рождения Ивана Михайловича Фёдорова (31.06.1924–1971)

– Иван Михайлович Фёдоровның тууына 100 ел (31.06.1924–1971)

**120** лет со дня рождения Гордея Ивановича Филиппова (01.01.1904–1982)

– Гордей Иванович Филипповның тууына 120 ел (01.01.1904–1982)

**100** лет со дня рождения Вильдана Саидовича Хабиева (10.09.1924–1945)

– Вильдан Сәет улы Хәбиевнең тууына 100 ел (10.09.1924–1945)

**100** лет со дня рождения Назипа Хазиповича Хазипова (10.02.1924–1945)

– Нәҗип Хаҗип улы Хаҗиповның тууына 100 ел (10.02.1924–1945)

**100** лет со дня рождения Акрама Мингазовича Хайрутдинова (01.02.1924–1944)

– Әкрам Минһаҗ улы Хәйретдиновның тууына 100 ел (01.02.1924–1944)

**100** лет со дня рождения Павла Семёновича Ханжина (20.06.1924–2007)

– Павел Семёнович Ханжинның тууына 100 ел (20.06.1924–2007)

**110** лет со дня рождения Зякрии Сяфитовича Хусяинова (07.03.1914–1944)

– Зәкәрия Сәфит улы Хөсәеновның тууына 110 ел (07.03.1914–1944)

**125** лет со дня рождения Филиппа Михайловича Черокманова (16.11.1899–1978)

– Филипп Михайлович Черокмановның тууына 125 ел (16.11.1899–1978)

**120** лет со дня рождения Марка Ивановича Шевелёва (11(24).10.1904–1991)

– Марк Иванович Шевелёвның тууына 120 ел (11(24).10.1904–1991)

**110** лет со дня рождения Евстафия Григорьевича Яковлева (27.04.1914–1945)

– Евстафий Григорьевич Яковлевның тууына 110 ел (27.04.1914–1945)

**80** лет со дня рождения Героя Российской Федерации Виктора Фёдоровича Ерина (17.01.1944–2018)

– Россия Федерациясе Герое Виктор Фёдорович Еринның тууына 80 ел (17.01.1944–2018)

# Юбилеи кавалеров ордена Славы трёх степеней – наших земляков в 2024 году*

# Якташларыбыз – Дан ордены тулы кавалерларының 2024 елдагы юбилейлары*

**100** лет со дня рождения Даяна Вагизовича Булатова (11.02.1924–1982)

– Даян Вагыйзь улы Булатовның тууына 100 ел (11.02.1924–1982)

**100** лет со дня рождения Рифката Хайрулловича Гайнуллина (11.01.1924–2009)

– Рифкать Хәйрулла улы Гайнуллинның тууына 100 ел (11.01.1924–2009)

**100** лет со дня рождения Павла Алексеевича Карпова (12.06.1924–2008)

– Павел Алексеевич Карповның тууына 100 ел (12.06.1924–2008)

**100** лет со дня рождения Тимура Гарафутдиновича Назмутдинова (27.12.1924–1977)

– Тимур Гарәфетдин улы Нәҗметдиновның тууына 100 ел (27.12.1924–1977)

**125** лет со дня рождения Николая Фёдоровича Пестонова (19.05.1899–1974)

– Николай Фёдорович Пестоновның тууына 125 ел (19.05.1899–1974)

**120** лет со дня рождения Михаила Никифоровича Скрементова (19.12.1904–1949)

– Михаил Никифорович Скрементовның тууына 120 ел (19.12.1904–1949)

**100** лет со дня рождения Курбана Тимергалиевича Тимергалиева (19.09.1924–1982)

– Корбан Тимергали улы Тимергалиевнең тууына 100 ел (19.09.1924–1982)

**110** лет со дня рождения Никиты Васильевича Фролова (1914–1945)

– Никита Васильевич Фроловның тууына 110 ел (1914–1945)

**100** лет со дня рождения Петра Герасимовича Филатова (15.07.1924–1980)

– Пётр Герасимович Филатовның тууына 100 ел (15.07.1924–1980)

**110** лет со дня рождения Василия Ивановича Филиппова (15.10.1914–1981)

– Василий Иванович Филипповның тууына 110 ел (15.10.1914–1981)

---

*** Очерки о жизненном пути Героев см.:**
**Геройларның тормыш юллары турындагы очеркларны кара:**
Кавалеры ордена Славы трёх степеней = Дан орденының тулы кавалерлары. – Казань: Книга Памяти, 2005. – 247 с. – На рус. и татар. яз.

# Юбилеи Героев Социалистического Труда – наших земляков в 2024 году*

# Якташларыбыз – Социалистик Хезмәт Геройларының 2024 елдагы юбилейлары*

**100** лет со дня рождения Усмана Гатаулловича Алиева (18.08.1924–1986)

– Госман Гатаулла улы Алиевның тууына 100 ел (18.08.1924–1986)

**110** лет со дня рождения Евгения Николаевича Батенчука (28.02.1914–1999)

– Евгений Николаевич Батенчукның тууына 110 ел (28.02.1914–1999)

**75** лет Геннадию Сергеевичу Баштанюку (22.10.1949)

– Геннадий Сергеевич Баштанюкка 75 яшь (22.10.1949)

**100** лет со дня рождения Александры Николаевны Беспаловой (01.09.1924–2010)

– Александра Николаевна Беспалованың тууына 100 ел (01.09.1924–2010)

**90** лет со дня рождения Абдулхая Халиковича Галиахметова (30.09.1934–2018)

– Габделхәй Халик улы Галиәхмәтовның тууына 90 ел (30.09.1934–2018)

**100** лет со дня рождения Михаила Петровича Гриня (03.10.1924–2003)

– Михаил Петрович Гриньның тууына 100 ел (03.10.1924–2003)

**90** лет со дня рождения Хамита Валеевича Зайдуллина (12.05.1934–1993)

– Хәмит Вәли улы Зәйдуллинның тууына 90 ел (12.05.1934–1993)

**100** лет со дня рождения Алексея Степановича Исаева (19.05.1924–1997)

– Алексей Степанович Исаевның тууына 100 ел (19.05.1924–1997)

**110** лет со дня рождения Серафима Ивановича Исаева (22.10 (по др. данным 22.12).1914–1989)

– Серафим Иванович Исаевның тууына 110 ел (22.10 (бүтән мәгълүматлар буенча 22.12).1914–1989)

---

***Очерки о жизненном пути Героев см.:**
**Геройларның тормыш юллары турындагы очеркларны кара:**

Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы – наши земляки = Социалистик Хезмәт геройлары һәм Хезмәт даны орденының тулы кавалерлары – безнең якташларыбыз. – Казань, 2003. – 232 с. – На рус. и татар. яз.
Герои Труда Татарии 1920–1938 гг.: док. очерки. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1974. – 304 с.
Герои Социалистического Труда (1938–1978 гг.): (док. очерки). – Казань: Татар. кн. изд-во, 1980. – 383 с.
Герои Социалистического Труда Татарии: док. очерки. Кн.2. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1984. – 352 с.

**110** лет со дня рождения Владимира Петровича Лушникова (29.05.1914–1985)

– Владимир Петрович Лушниковның тууына 110 ел (29.05.1914–1985)

**90** лет со дня рождения Гульсум Мифтаховны Мингазовой (Шамгуновой; 1934–2012)

– Гөлсем Мифтах кызы Минһаҗева (Шәмгунова) ның тууына 90 ел (1934–2012)

**100** лет со дня рождения Александры Ивановны Николаевой (06.01.1924–2015)

– Александра Ивановна Николаеваның тууына 100 ел (06.01.1924–2015)

**100** лет со дня рождения Николая Ивановича Похлёбкина (17.12.1924–2022)

– Николай Иванович Похлёбкинның тууына 100 ел (17.12.1924–2022)

**100** лет со дня рождения Василия Никитовича Прохорова (1924–1992)

– Василий Никитович Прохоровның тууына 100 ел (1924–1992)

**110** лет со дня рождения Константина Александровича Сергиевского (13.11.1914–1994)

– Константин Александрович Сергиевскийның тууына 110 ел (13.11.1914–1994)

**80** лет Любовь Евгеньевне Смирновой (16.07.1944)

– Любовь Евгеньевна Смирновага 80 яшь (16.07.1944)

**100** лет со дня рождения Георгия Степановича Сторожева (1924–1994)

– Георгий Степанович Сторожевның тууына 100 ел (1924–1994)

## Юбилей полного кавалера ордена Трудовой Славы – нашего земляка в 2024 году*

## Якташыбыз – Хезмәт Даны ордены тулы кавалерының 2024 елдагы юбилее*

**75** лет Данилу Зияфовичу Фатхуллину (02.01.1949)

– Данил Зияф улы Фәтхуллинга 75 яшь (02.01.1949)

***Очерк о жизненном пути Героя см.:**
**Геройның тормыш юлы турындагы очеркны кара:**
Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы – наши земляки = Социалистик Хезмәт геройлары һәм Хезмәт даны орденының тулы кавалерлары – безнең якташларыбыз. – Казань, 2003. – С. 223. – На рус. и татар. яз.

# СПРАВОЧНО-БИОГРАФИЧЕСКИЕ И БИБЛИОГРАФИЧЕСКИЕ СВЕДЕНИЯ

# БЕЛЕШМӘ-БИОГРАФИК ҺӘМ БИБЛИОГРАФИК МӘГЪЛҮМАТЛАР

## 10 февраля / февраль



### Рафкат Бикчантаев
### Рәфкать Бикчәнтәев

1924–1975

100 лет со дня рождения
тууына 100 ел

Драматический актёр, режиссёр, педагог Рафкат Ахметзянович Бикчантаев родился 10 февраля 1924 года в деревне Нижняя Береске Атнинского района Татарской АССР в семье крестьянина. В начале 1930 годов семья переезжает в Казань. Закончив в 1939 году семилетнюю школу, Рафкат, с детства увлекающийся рисованием, поступает в Казанское художественное училище.

С начала Великой Отечественной войны он работает на заводе имени Горбунова, а также возобновляет учёбу во временно закрытом училище, которое оканчивает в 1944 году.

В годы работы на заводе Рафкат Бикчантаев также принимает участие в художественной самодеятельности, посещает татарский народный театр, знакомится с основами театрального искусства.

В 1944 году его отправляют учиться в Татарскую студию актёрского факультета ГИТИСа им. А.В.Луначарского. Успешно закончив учёбу в 1949 году, он возвращается в Казань и начинает работать в татарской труппе Казанского театра юного зрителя.

В 1950–1971 годах Р.Бикчантаев актёр и режиссёр Татарского государственного академического театра им. Г.Камала; с 1971 года режиссёр Республиканского передвижного театра (ныне Татарский государственный театр драмы и комедии им. К.Тинчурина). В 1965–1970 годах преподаёт в Казанском театральном училище.

Р.Бикчантаев – актёр большого дарования, работая над ролью, стремился выявить парадоксальные противоречия характера персонажа, показать его отрицательные стороны, вызывать сочувствие к нему, соединял в образе комическое и трагическое начало, заставляя задуматься над сложностью и неоднозначностью личности любого масштаба.

Основные роли: Гофмаршал – «Коварство и любовь» Ф.Шиллера; Апсалям, Марс, Гайфи – «Первая любовь», «Добро пожаловать», «Если улыбнётся счастье» Х.Вахита; Сиразетдин – «Банкрот» Г.Камала; Нигметзян, Абдулич – «Гульджамал», «Бегство» Н.Исанбета; Карим – «Тайны, поведанные земле» А.Гилязова; Джантай – «Тополёк мой в красной косынке» Ч.Айтматова и др.

Свою режиссёрскую деятельность Р.Бикчантаев начинает с постановок на сцене Татарского государственного академического театра им. Г.Камала: «Минем хатын» («Моя жена», 1955) М.Амира; «Азат» (1963) Т.Миннуллина; «Беренче мәхәббәт» («Первая любовь», 1960), «Рәхим итегез» («Добро пожаловать», 1961), «Кайда соң син?» («Где же ты?», 1963), «Күк капусы ачылса» («Если улыбнётся счастье», 1967) Х.Вахита и др. Эти постановки отмечены яркой театральностью, праздничностью, заразительным оптимизмом. Серьёзностью размышлений и одновременно тонкой лиричностью окрашен спектакль «Җиргә тапшырылган серләр» («Тайны, поведанные земле», 1967) по пьесе А.Гилязова.

В Республиканском передвижном театре Бикчантаевым поставлены спектакли: «Айгөл иле» («Страна Айгуль») М.Карима, «Әтиең мин синең» («Я твой отец») Я.Ялунера, «Туйлар узгач» («После свадьбы») Р.Батуллы, «Ситуация» В.С.Розова, «Хөрмәне бушка бирмиләр» («Финики даром не дают») С.Джамала.

За постановку спектакля «Беренче мәхәббәт» («Первая любовь») Х. Вахита на сцене Татарского государственного театра им. Г.Камала, Р. Бикчантаев в 1960 году удостоился Государственной премии Татарстана им. Г.Тукая.

Рафкат Бикчантаев умер 27 января 1975 года.

Драма актёры, режиссёр, педагог Рәфкать Әхмәтҗан улы Бикчәнтәев 1924 елның 10 февралендә Татарстан АССРның Әтнә районы Түбән Бәрәскә авылында крестьян гаиләсендә туа.

1930 нчы еллар башында гаилә Казанга күченә. 1939 елда җидееллык мәктәпне тәмамлагач,

кечкенәдән рәсемнәрне тере, җанлы итеп ясый белүче Рәфкать Казан сынлы сәнгать училищесына укырга керә.

Бөек Ватан сугышы башлангач, Горбунов исемендәге заводта эшли башлый. Вакытлыча ябылып торган училищелары яңадан ачылгач, Рәфкать шунда кире кайтып, заводтагы эшеннән аерылмый гына укуын дәвам итә һәм аны 1944 елда тәмамлап чыга.

Рәфкать Бикчәнтәевнең иҗат юлы заводта эшләгәндә үзешчән сәнгатьтә башлана. Ул татар халык театрына йөреп, театр сәнгате серләре белән таныша. Акрынлап сәхнә аны үзенә тарта. 1944 елда ул А.В.Луначарский исемендәге Мәскәү дәүләт театр институты каршындагы Татар студиясенә укырга җибәрелә. 1949 елда аны уңышлы тәмамлаганнан соң, Казанга кайта һәм Казан яшь тамашачылар театрының татар труппасында эшли башлый.

1950–1971 елларда Р.Бикчәнтәев Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында актёр һәм режиссёр, 1971 елдан Республика күчмә театрында (хәзер К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры) режиссёр булып эшли. 1965–1970 елларда Казан театр училищесында укыта.

Р.Бикчәнтәев – зур талантлы актёр буларак, рольне әзерләгәндә характерның каршылыкларын ачарга, тискәре якларын күрсәтергә, аңа карата кызгану хисе уятырга омтыла; образда комик һәм трагик башлангычларны берләштереп, шәхеснең катлаулылыгы, кабатланмас характеры турында уйландыра.

Төп рольләре: Ф.Шиллерның «Мәкер һәм мәхәббәт»ендә – Гофмаршал; Х.Вахитның «Беренче мәхәббәт», «Рәхим итегез», «Күк капусы ачылса»сында – Әпсәләм, Марс, Гайфи; Г.Камалның «Банкрот»ында – Сиражетдин; Н.Исәнбәтнең «Гөлҗамал», «Һиҗрәт»ендә – Нигъмәтҗан, Абдулич; А.Гыйләҗевнең «Җиргә тапшырылган серләр»ендә – Кәрим; Ч.Айтматовның «Гүзәлем Әсәл»ендә – Җантай һ.б.

Р.Бикчәнтәев режиссёрлык эшчәнлеген Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә башлый. М.Әмирнең «Минем хатын» (1955), Т.Миңнуллинның «Азат» (1963), Х.Вахитның «Беренче мәхәббәт» (1960), «Рәхим итегез» (1961), «Кайда соң син?» (1963), «Күк капусы ачылса» (1967) пьесалары буенча һәм башка спектакльләр чыгара. Бу спектакльләр ачык театральлек, бәйрәмчә тантаналылык, тәэсирле оптимизм белән аерылып торалар. А.Гыйләҗев пьесасы буенча куелган «Җиргә тапшырылган серләр» (1967) спектакле җитди уйлануларга һәм бер үк вакытта нечкә лиризмга бай.

Республика күчмә театрында М.Кәримнең «Айгөл иле», Я.Ялунерның «Әтиең мин синең», Р.Батулланың «Туйлар узгач», В.С.Розовның «Ситуация», С.Җамалның «Хөрмәне бушка бирмиләр» әсәрләрен сәхнәгә куя.

1960 елда Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә Х.Вахитның «Беренче мәхәббәт» пьесасын сәхнәгә куйган өчен Р.Бикчәнтәевкә Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелә.

Рәфкать Бикчәнтәев 1975 елның 27 гыйнварында вафат була.

## Советуем прочитать: Укырга тәкъдим итәбез:


**Арсланов М.Г.** Татарское режиссёрское искусство (1957–1990). – Казань: Фикер, 2002. – 272 с. – Приход молодых драматургов. Режиссура Р.Бикчентаева. Эволюция его творческого союза с Х.Вахитом. «Первая любовь», «Где же ты?», «Если улыбнётся счастье». – С.16–38.

**Рәфкать Бикчәнтәев:** истәлекләр / [авт.-төз. Ю.Г.Сафиуллин]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 279 б.: портр., фот.

**Рәфкать Бикчәнтәев:** истәлекләр / [авт.-төз., кереш сүз авт. Ю.Г. Сафиуллин]. – Казан: «Ак бүре» нәшрияты, 2018. – 279 б.: фоторәс б-н.

**Арсланов Г.** Тылсым. Татар театры: режиссёрлар һәм драматурглар. – Казан: Мәгариф, 2008. – 287 б. – Якты йолдыз иде (Рәфкать Бикчәнтәев). – Б. 182–190.

**Арсланов М.Г.** Татар театры: энциклопедик сүзлек-белешмә. – Казан: Заман, 2014. – 583 б. – Бикчәнтәев Рәфкать Әхмәтҗан улы. – Б. 79–83.

**Шәймиев М.** Истә, һаман да истә // Сәхнә. – 2019. – № 2. – Б. 18.

**Сафиуллин Ю.** Юксындырып искә төшә һаман // Сәхнә. – 2019. – № 2. – Б. 19–21.

**Сафиуллин Ю.** Онытылмас сәхнә йолдызы // Мәдәни җомга. – 2019. – 8 февр., – Б. 12–14.

**Хәбибуллина Л.** Театрның йөрәге Бәрәскәдә тибә // Шәһри Казан. – 2014. – 18 февраль. – Б. 5.

## март




## Журнал «Ялкын»
## «Ялкын» журналы

### 1924

### 100 лет со дня выхода первого номера
### Беренче саны чыгуга 100 ел

«Ялкын» – ежемесячный иллюстрированный литературно-художественный детский журнал. 20 марта 1924 года в Москве на татарском языке увидел свет первый номер детского журнала «Кечкенә иптәшләр». Журнал печатался на арабской графике. В 1928 году название сменилось на «Октябрь баласы», начал издаваться на латинской графике. С 1933 года журнал издаётся в Казани под названием «Пионер каләме».

В 1941 году, когда началась Великая Отечественная война, журнал перестал выходить. В 1952 году издание журнала было возобновлено под названием «Пионер». В 1957 году журнал «Пионер», из-за большого количества данного названия по всей стране, был переименован в «Ялкын».

Организатор журнала – поэт Муса Джалиль. Первым редактором был Х.Курмаев. Затем работают М.Джалиль, Р.Хамиди, Л.Гильми, Г.Хабибуллин, А.Ахмет, Л.Ихсанова, Г.Мухаметшин, Р.Хафизова, Р.Туфитуллова, З.Дарзаманов, Э.Закирова, Ю.Миннуллина, А.Гимадиев, с 2017 года И.Фазуллин.

На страницах журнала размещаются произведения нескольких поколений писателей и поэтов. Среди авторов – А.Алиш, А.Кутуй, Ш.Усманов, Дж.Тарджеманов, Ш.Мударрис, М.Аглямов, Р.Зайдулла, Л.Лерон, С.Гаффарова, Л.Янсуар и др.

Журнал адресован подросткам 10–16 лет, в центре внимания – их жизнь, интересы и проблемы. Печатаются материалы дидактического характера, литературные произведения. Своими публикациями о культуре и искусстве «Ялкын» стремится воспитывать художественный вкус у подрастающего поколения. Большое место отводится материалам о кумирах молодёжи, интервью с видными представителями татарской культуры.

За 100 лет своего существования журнал «Ялкын» помог многим талантливым молодым людям найти себя. Потому что многие будущие писатели, журналисты первые шаги к творчеству начинали написав для журнала статьи и участвуя в конкурсах. В каждом номере журнала публикуются лучшие стихи, рассказы, сказки, написанные юными читателями. Страницы журнала украшают рисунки детей. За лучшие произведения детям вручаются памятные подарки.

В последние годы журнал полностью изменился. Он стал современным, динамичным и по содержанию, и по оформлению, и по подаче материалов.

Журнал «Ялкын» удостоен премий «Бәллүр каләм–Хрустальное перо» Союза журналистов РТ (1999, 2005), имени А.Алиша Союза писателей Республики Татарстан (2006.), Республиканской премии им. М.Джалиля (2011). Награждён орденом «Знак Почёта».

«Ялкын» – урта һәм олы яшьтәге мәктәп балаларының айлык әдәби-нәфис, рәсемле журналы. 1924 елда Муса Җәлилнең балалар өчен журнал чыгарырга кирәклеге турындагы мәкаләсе басылып чыга. 1924 елның 20 мартында Мәскәүдә «Кечкенә иптәшләр» дип аталучы балалар журналының беренче саны дөнья күрә. Журнал гарәп графикасында була. 1928 елдан, латин графикасына күчеп, «Октябрь баласы» дип атала башлый. 1933 елда журнал Казанга кайта, «Пионер каләме»нә әверелә.

1941 елда, Бөек Ватан сугышы башлангач, журнал чыгудан туктатыла. 1952 елда ул «Пионер» исеме белән яңадан дөнья күрә. Ә 1957 елда, «Пионер» исемле журналлар бөтен ил буенча күбәеп китү сәбәпле, «Ялкын»га үзгәртелә.

«Ялкын» журналын оештыручы – шагыйрь М.Җәлил. Аның беренче редакторы Х.Курмаев була. Аннары М.Җәлил, Р.Хәмиди, Л.Гыйльми, Г.Хәбибуллин, А.Әхмәт, Л.Ихсанова, Г.Мөхәммәтшин, Р.Хафизова, Р.Туфитуллова, Җ.Дәрзаманов, Э.Закирова, Й.Миннуллина, 2017 елдан И.Фазуллин эшлиләр.

Журнал битләрендә берничә буын язучыларның һәм шагыйрьләрнең әсәрләре урын ала. Алар арасында: А.Алиш, Г.Кутуй, Ш.Усманов, Җ.Тәрҗеманов, Ш.Мөдәррис, М.Әгъләмов, Р.Зәйдулла, Л.Лерон, С.Гаффарова, Л.Янсуар һ.б. бар.

Журнал 10–16 яшьлек яшүсмерләргә юнәлтелә, игътибар үзәгендә – аларның тормышы, мәнфәгатьләре һәм проблемалары. Дидактик характердагы материаллар, әдәби әсәрләр басыла. Мәдәният һәм сәнгать турындагы мәкаләләр белән «Ялкын» үсеп килүче буында сәнгати зәвык тәрбияләргә омтыла. Яшьләрнең кумирлары турындагы мәкаләләргә, татар мәдәниятенең күренекле эшлеклеләре белән әңгәмәләргә зур урын бирелә.

«Ялкын» журналы 100 ел эчендә бик күп талантлы яшьләргә үз-үзләрен табарга ярдәм итә. Чөнки булачак язучыларның, журналистларның күбесе иҗатка беренче адымнарын аңа мәкаләләрен җибәреп, конкурсларда катнашып башлыйлар. Журналның һәр санында укучы балалар язган иң яхшы шигырьләр, хикәяләр, әкиятләр дөнья күрә. Басманың һәр саны сәхифәләрен балалар ясаган рәсемнәр бизи. Иң яхшы дип табылган әсәрләре өчен балаларга истәлекле бүләкләр тапшырыла.

Соңгы елларда журнал тулысынча диярлек үзгәрде. Ул эчтәлеге җәһәтеннән дә, бизәлеш ягыннан да, материаллар бирү буенча да заманчалашты, даими динамик үсештә.

«Ялкын» журналы Татарстан Республикасы Журналистлар берлегенең «Бәллүр каләм – Хрустальное перо» (1999, 2005), Татарстан Язучылар берлегенең А.Алиш исемендәге (2006) бүләкләренә, М.Җәлил исемендәге Республика премиясенә (2011) лаек була. «Почёт билгесе» ордены белән бүләкләнә.

## Советуем прочитать:
## Укырга тәкъдим итәбез:

**Татарская периодическая печать: научно-энциклопедическое издание**. – Казань: Ин-т татарской энциклопедии и регионоведения АН РТ, 2017. – 199 с. – «Ялкын». – С. 153.

**Казанская периодика XIX–XXI вв.: энциклопедический спр. для представителей средств массовых коммуникаций.** – Казань: Ин-т татарской энциклопедии и регионоведения АН РТ: Татар. кн. изд-во, 2018. – 197 с. «Ялкын». – С. 191–192.

**Иванычева О.** Девяностолетний юбилей отметил журнал «Ялкын» // Казанские ведомости. – 2014. – 16 апр.

**Закирова Э.** Җылынды синең учакта, җылынды ничә буын!. // Безнең мирас. – 2019. – № 3. – Б. 60–67.

**Закирова Э.** «Ялкын»лы көннәремнән... // Ялкын. – 2018. – № 4. – Б. 42–43.

**Шиһапова Г.** Зурларча сөйләшү // Ватаным Татарстан. – 2019. – 26 март. – Б. 2.

**Абдрахманова А.** Дуслык күпере // Ялкын. – 2019. – № 4. – Б. 16–19.

**Пыскып янмасын, дөрләсен!** // Ватаным Татарстан. – 2014. – 8 май. – Б. 18.

# 15 апреля / апрель



## Самат Шакир

1924–1998

100 лет со дня рождения
тууына 100 ел

Писатель Самат Шакир (Самат Фатхрахманович Шакиров) родился 15 апреля 1924 года в селе Кубян Атнинского района Татарской АССР. После окончания семилетней школы, учится в Арском педагогическом училище.

Потом работает учителем в Нусинской сельской школе, литературным сотрудником в Атнинской районной газете и в 1942–1943 годах – заведующим школой в деревне Янга-Аул Кзыл-Юлского района.

В 1943 году призывается в ряды Советской Армии и служит под Сталинградом.

После демобилизации некоторое время работает литературным сотрудником в редакции газеты «Кызыл Татарстан», потом в 1946–1949 годах – ответственным секретарём Дубъязской районной газеты.

В 1951 году С.Шакиров поступает на историко-филологический факультет Казанского государственного университета. Через год переводится на заочное отделение и едет учителем в Сикертанскую школу Чурилинского района Татарской АССР. В 1954–1958 годах работает директором Муралинской средней общеобразовательной школы Кайбицкого района.

После окончания университета С.Ф.Шакиров переезжает в Казань и в 1958–1962 годах работает редактором в Татарском книжном издательстве. В 1962 году он становится членом Союза писателей и как писатель-профессионал посвящает себя творчеству.

Самат Шакир своё литературное творчество начинает с написания стихов. В 1939 году в журнале «Пионер каләме» («Пионерское перо») было опубликовано его первое стихотворение «Урман» («Лес»). После этого очень часто печатаются его многочисленные стихотворения, посвящённые школьной жизни, родной природе, темам гражданской и Великой Отечественной войн, в периодической печати и выходят отдельными сборниками, в основном, адресованными школьникам.

Тем не менее, творческое лицо С.Шакира определяют произведения прозы – очерки, документальные повести. Писатель ведёт эффективную работу по поиску документальных материалов, касающихся событий Великой Отечественной войны и их подготовке к печати. Автор много ездит, скрупулёзно изучает материалы о наших земляках, посещает места боёв, корпит в архивах, встречается с ветеранами войны – старыми солдатами, бывшими партизанами, военачальниками. Таким образом он собирает документальные материалы для своих произведений.

В 1964 году выходит его первая книга – книга очерков «Үлемсезләр» («Бессмертные») о 28 панфиловцах. Наибольший успех получила его документальная повесть «Легенда егетләре» («Парни легенды»), опубликованная в 1965 году. Эта книга о трёх воинах, героически погибших в боях за Сталинград – испанском парне, капитане Рубене Ибаррури, русском лётчике-майоре Владимире Каменщикове, татарском парне-артиллеристе, капитане Хафизе Фаттахутдинове. Впоследствии эта книга была переведена на русский и туркменский языки, отрывки из книги на башкирский, казахский, чувашский, марийский, удмуртский языки.

Он опубликовал отдельной книгой «Сугыш язмалары» («Летопись войны», 1967) – фронтовые дневники и стихи татарского поэта, полковника Советской Армии Хайрутдина Музая, погибшего в фашистском плену, написал очерк о жизни и творчестве писателя. Он также автор-составитель сборника «Алар сафта» («Они в строю», 1961, 1985) включающий в себя произведения двадцати девяти татарских писателей, погибших на полях Великой Отечественной войны.

С.Шакир активно работает и в области перевода. Он переводит на татарский язык произведения русских, украинских, казахских, киргизских поэтов.

Издано около сорока книг Самата Шакира – авторских и в качестве составителя, это: поэтические сборники, повести, книги очерков, записок и статей.

В 1984 году С.Шакиру присвоено почётное звание заслуженного работника культуры Татарской АССР.

28 октября 1998 года С.Шакир умер. Похоронен на Сухорецком кладбище города Казани.

Язучы Самат Шакир (Самат Фәтхерахман улы Шакиров) 1924 елның 15 апрелендә Татарстан АССРның Әтнә районы Күәм авылында туа. Җидееллык мәктәпне тәмамлагач, Арча педагогия училищесында укый. Аннары Носы авылы мәктәбендә укытучы, Әтнә район газетасы редакциясендә әдәби хезмәткәр һәм 1942–1943 елларда Кызыл Юл районындагы Яңавылда мәктәп мөдире булып эшли. 1943 елда Совет Армиясенә алына һәм Сталинград янында хезмәт итә. Армиядән кайткач, бераз вакыт «Кызыл Татарстан» газетасы редакциясендә әдәби хезмәткәр, аннан соң, 1946–1949 елларда, Дөбъяз районы газетасының җаваплы сәркятибе була.

1951 елда С.Шакир Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында укый

башлый. Бер елдан читтән торып уку бүлегенә күчеп, Чүриле районының Сикертән авылы мәктәбенә укытучы булып китә. 1954-тә һәм аннан соңгы елларда Кайбыч районы Мөрәле мәктәбендә директор булып эшли.

Университетны тәмамлагач, С.Шакир Казанга күченеп килә һәм 1958–1962 елларда Татарстан китап нәшриятында редактор булып эшли. 1962 елда Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп алынгач, профессиональ язучы булып иҗат итә.

С.Шакир әдәби иҗат эшчәнлеген шигырь язудан башлый. 1939 елда «Пионер каләме» журналында «Урман» дигән беренче шигыре басылып чыга. Шуннан соң аның мәктәп тормышы, туган як табигате, гражданнар сугышы, Бөек Ватан сугышы темаларына багышланган һәм, нигездә, мәктәп балаларына атап язылган күпләгән шигырьләре көндәлек матбугатта да, аерым җыентыклар булып та бик еш басыла.

Шулай да, Самат Шакирның иҗади йөзен, поэзиядән бигрәк, проза әсәрләре – очерклары, документаль повестьлары билгели. Язучы Бөек Ватан сугышы вакыйгаларына кагылышлы документаль материалларны эзләп табу, аларны матбугатка әзерләп чыгару юнәлешендә нәтиҗәле эш алып бара. Автор күп йөри, эзләнә, дәһшәтле сугышлар булган урыннарга бара, архивларда казына, сугыш ветераннары – карт солдатлар, элекке партизаннар, хәрби начальниклар белән очраша. Әнә шулай үзенең әсәрләре өчен документаль материаллар җыя.

1964 елда С.Шакир хәрби-патриотик темага багышланган беренче китабын – «Үлемсезләр» дип исемләнгән, легендар 28 панфиловчы турындагы очерклар китабын бастыра. Аның 1965 елда басылып чыккан «Легенда егетләре» исемле документаль повесте аеруча зур уңыш казана. Сталинград өчен сугышларда батырларча һәлак булган өч егет – испан егете, капитан Рубен Ибаррури, рус егете, очучы-майор Владимир Каменщиков, татар егете, артиллерист-капитан Хафиз Фәттахетдинов турындагы бу китап соңыннан рус һәм төрекмән, өзекләре башкорт, казакъ, чуваш, мари, удмурт телләренә тәрҗемә ителә. Язучының «Ташлардагы язулар» (1975), «Үлемне җиңгән батыр» (1975), «Исемнәре мәрмәрдә» (1982) кебек очерклар китаплары укучылар һәм әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан уңай каршы алына.

Ул татар шагыйре, Совет Армиясе полковнигы, фашист тоткынлыгында һәлак булган Хәйретдин Мөҗәйнең фронт көндәлекләрен һәм шигырьләрен – «Сугыш язмалары»н – аерым китап итеп бастырып чыгара (1967), язучының тормышы һәм иҗаты турында очерк яза. Шулай ук ул Ватан сугышы кырларында һәлак булган егерме тугыз татар совет язучысының әсәрләрен, биографик белешмәләрен үз эченә алган «Алар сафта» җыентыкларының (1961, 1985) автор-төзүчесе дә.

С.Шакир тәрҗемә өлкәсендә дә актив эшли. Ул рус, украин, казакъ, кыргыз шагыйрьләренең әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә.

Прозаик, шагыйрь һәм журналист С.Шакирның кырыкка якын исемдәге китаплары басылып чыга.

1984 елда С.Шакирга Татарстан АССРның атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исем бирелә.

1998 елның 28 октябрендә Самат Шакир вафат була. Казан шәһәренең Коры Елга зиратына җирләнә.

## Советуем прочитать:
## Укырга тәкъдим итәбез:

**Самат Шакир:** биобиблиографик күрсәткеч / Татарстан Республикасы Милли китапханәсе; төз. З.С.Шакирова-Нуриева; мөх-ре И.Г.Һадиев. – Казан: Милли китап, 2003. – 286 б. – («Татар әдипләре» сер.). – Татар, рус һәм инглиз телләрендә.

**Шакир С.** Яраннар чәчәк аткан: шигырьләр, поэмалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. – 155 б.

**Шакир С.** Мәңгелек исемлектә: очерклар, язмалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. – 107 б.

**Шакир С.** Кыңгырау чәчәкләр: шигырьләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. – 47 б.

**Шакир С.** Төнбоеклы күл буенда: шигырьләр, поэма / кереш сүз язучы З.Шакирова-Нуриева. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. – 351б.: портр. б-н.

**Гиниятуллина А.** Писатели Советского Татарстана: биобиблиогр. спр. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1970. – 511 с. – Самат Шакир. – С. 484–485.

**Манасыпов Ф.** Верность долгу и памяти // Коммунист Татарии. – 1990. – № 5 . – С. 38–42. – То же в парал. изд. на татар. яз.

**Әдипләребез:** биобиблиогр. белешмәлек. 2 томда. Т. 2 / [төз. Р.Н.Даутов, Р.Ф.Рахмани]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 735 б. – Самат Шакир. – Б. 634–636.

**Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б.** Совет Татарстаны язучылары: биобиблиогр. белешмә. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – 639 б. – Самат Шакир. – Б. 542–544.

**Шакирова-Нуриева З.** Безнең әти // Мәдәни җомга. – 2014. – 8 май. – Б. 18.

**Кәримов К.** Боз кичү // Казан утлары. – 2004. – № 4. – Б. 174–175.

**Исламов Ф.** Сугыш темасын яктырткан каләм иясе // Шәһри Казан. – 2005. – 6 май.

**Гыйззәтуллин Р.** Эзтабар әдип иде // Мәдәни җомга. – 2014. – 8 май. – Б. 18.

**Садриева А.** Музей – патриотик тәрбия үзәге: [Татарстанның Әтнә районы Күәм урта мәктәбендә С.Шакир музее эшли] // Мәгариф. – 2015. – № 5. – Б. 23.

## 6 июня / июнь



### Александр Сергеевич Пушкин

**1799–1837**

**225 лет со дня рождения**
**туувына 225 ел**

Александр Сергеевич Пушкин – поэт, прозаик, родоначальник новой русской литературы, создатель русского литературного языка, один из самых авторитетных литературных деятелей первой трети XIX века. Он – автор многочисленных стихотворений, поэм, драматических произведений, сказок, публицистических статей.

В сентябре 1833 года А.С.Пушкин, по пути в Оренбург, посетил Казань с целью сбора материала для историко-документального романа о событиях Крестьянской войны 1773–1775 годов под предводительством Е.И.Пугачёва. Прибыл в Казань в ночь с 5 на 6 сентября. На следующий день в Суконной слободе встретился с суконщиком В.П.Бабиным, который (со слов своих родителей-очевидцев) рассказал поэту о событиях июля 1744 года.

7 сентября Пушкин познакомился с К.Ф.Фуксом, о котором в примечаниях к роману «История Пугачёва» (1834) написал: «Ему обязан я многими любопытными известиями касательно эпохи и стороны, здесь описанных». Пушкин посетил место бывшей ставки Пугачёва у деревни Нокса, Арское поле (ныне в черте города) и Кремль, встретился с Крупениковым, который юношей был захвачен пугачёвцами в плен. 8 сентября Пушкин выехал из Казани, в дороге в своём дневнике он отметил: «Здесь я возился со стариками, современниками моего героя, объезжал окрестности города, осматривал места сражений, расспрашивал, записывал и остался очень доволен, что не напрасно посетил эту сторону».

Пушкин был удовлетворён результатами пребывания в Казани. Собранные материалы поэт использовал в работе над «Капитанской дочкой» и «Историей Пугачёва». Казанские встречи и личные впечатления помогли ему создать произведения, в деталях содержащие реальные сведения. Он продолжал поддерживать связи с казанцами. Кратковременное пребывание Пушкина в Казани оставило яркий след в передовых кругах казанского общества.

Появление поэзии Пушкина в татарском общественном сознании приходится на начало XX века. Определённая часть интеллигенции, знакомая с русской культурой, знали Пушкина и раньше. Самый большой вклад в первые переводы лирики Пушкина внёс, как известно, Габдулла Тукай. Им переводились около десяти стихотворений. Одновременно с Г.Тукаем лирику Пушкина переводят Дэрдменд, С.Сунчелей, Г.Рахманкулый и др.

В советское время, особенно после образования Союза писателей Татарстана, перевод произведений Пушкина был систематизирован. Почти все значимые произведения поэта переведены на татарский язык. Во второй половине 1930-х годов начинают его переводить А.Кутуй, М.Джалиль, А.Исхак, А.Файзи, А.Ерикей. Некоторые произведения Пушкина переводятся на татарский язык разными писателями в нескольких вариантах:

«Евгений Онегин» был переведён на татарский в 1939 году Ф.Бурнашем, а после войны это сделали каждый по-своему А.Исхаки и Ш.Маннур. Круг переводчиков лирики Пушкина всё время расширялся новыми именами: М.Максуд, А.Шамов, С.Баттал, Н.Арсланов, Г.Шамуков, З.Нури, Ш.Маннапов, Зульфат, Л.Шагирзян, Н.Акмалов и др. Творчество А.С.Пушкина на татарском языке интересно не только писателям, литературоведам, но и широкому кругу читателей.

В 1899, в год 100-летия со дня рождения поэта, при Казанском университете было учреждено Общество любителей русской словесности в память А.С.Пушкина. В этом же году улицы Верхняя Фёдоровская и 1-я Театральная были переименованы в улицу Пушкина. В 1956 году у здания Государственного театра оперы и балета им. М.Джалиля установлен памятник поэту (скульптор Н.К.Вентцель).

С 2019 года в Казани действует Культурный центр имени А.С.Пушкина.

Александр Сергеевич Пушкин – шагыйрь, прозаик, яңа рус әдәбиятына нигез салучы, рус әдәби телен булдыручы, XIX гасырның беренче өчлегендә иң абруйлы әдәбият эшлеклеләренең берсе. Ул күпсанлы шигырьләр, поэмалар, драма әсәрләре, әкиятләр, публицистик мәкаләләр авторы.

Е.И.Пугачёв җитәкчелегендәге 1773–1775 елгы Крестьяннар кузгалышы турында тарихи-документаль роман язу нияте белән 1833 елның сентябрендә Пушкин, Оренбургка барышлый, Казанда булып китә. Шәһәргә ул 5 сентябрьдән 6 сентябрьгә каршы төндә килә. Икенче көнне Постау бистәсендә сукночы В.П.Бабин белән очраша. Ул шул көннәрнең шаһите булган әти-әнисе сүзләреннән чыгып, шагыйрьгә 1774 елның июль вакыйгалары турында сөйли.

7 сентябьдә Пушкин К.Ф.Фукс белән таныша. Аның турында «Пугачёв тарихы» («История Пугачёва», 1834) романының искәрмәләрендә болай дип яза: «Мин аңа биредә тасвирланган чор һәм шушы як турында күп кызыклы мәгълүматлар ала алганым өчен бик рәхмәтлемен». Башта Пугачёв ставкасы урнашкан урынга – Нокса авылына, Арча кырына (хәзер Казан шәһәре эчендә) һәм Кремльгә бара, яшүсмер чагында пугачёвчылар тарафыннан кулга алынган сәүдәгәр Л.Ф.Крупеников белән очраша. 8 сентябрьдә Пушкин Казаннан китеп бара, юлда үзенең көндәлегенә: «Биредә мин картлар, минем геройның замандашлары белән кайнаштым, шәһәр читләрен урап уздым, сугыш барган урыннарны карап чыктым, сораштым, язып алдым һәм бу җирләргә килеп чыгуыма бик ризамын», – дип яза.

Пушкин Казанда булуыннан канәгать кала. Шагыйрь җыелган материалларны «Капитан кызы» һәм «Пугачёв тарихы» әсәрләрен язганда куллана. Казандагы очрашулары һәм алган тәэсирләре аңа реаль мәгълүматлар булган әсәрләр язарга ярдәм итә. Ул казанлылар белән элемтәләрен өзми, аралашуын дәвам итә. Пушкинның Казанда кыска гына вакыт аралыгында булуы да Казан җәмәгатьчелегенең алдынгы даирәләрендә якты эз калдыра.

А.С.Пушкин иҗатының татарларда чын мәгънәсендә тарала башлавы XX гасыр башына туры килә. Әлбәттә, рус мәдәнияте белән беркадәр таныш булган мәгълүм зыялылар катламы Пушкинны күпкә элегрәк белгәндер. Билгеле булганча, Пушкинның беренче тәрҗемәләренә иң зур өлешне Габдулла Тукай кертә. Аның тарафыннан барлыгы унлап шигырь тәрҗемә ителә. Тукай белән бер үк вакытта Пушкин лирикасын Дәрдмәнд, С.Сүнчәләй, Г.Рахманколый һ.б. да тәрҗемә итә.

Совет чорында, бигрәк тә Татарстан Язучылар берлеге оешкач, Пушкинны тәрҗемә итү эзлекле бер системага салына. Шагыйрьнең күләмле әсәрләренең бөтенесе диярлек татарчага тәрҗемә ителгән. 1930 нчы елларның икенче яртысында аны Г.Кутуй, М.Җәлил, Ә.Исхак, Ә.Фәйзи, Ә.Ерикәйләр тәрҗемә итә. Пушкинның кайбер әсәрләре хәтта берничә тапкыр төрле авторлар тарафыннан тәрҗемәләнгән: «Евгений Онегин»ны Ф.Бурнаш 1939 елда ук татарчалаштырган булган, сугыштан соң шул ук әсәр Ә.Исхак һәм Ш.Маннурлар тарафыннан үзләренчә яңадан тәрҗемә ителә. Пушкинны татар укучысына җиткерүне бик күп татар әдипләре дәвам итә. Алар арасында: М.Максуд, А.Шамов, С.Баттал, Н.Арсланов, Г.Шамуков… Пушкин лирикасын тәрҗемә итүчеләрнең саны һәрвакыт арта бара һәм яңа исемнәр белән тулылана: З.Нури, Ш.Маннапов, Зөлфәт, Л.Шагыйрьҗан, Н.Акмалов һ.б.

Пушкинның татар теленә тәрҗемә ителә башлавына 100 елдан артты. Шушы вакыт эчендә татар язуында ике графика реформасы үткәрелде. Рус шагыйренең беренче тәрҗемәләре гарәп хәрефләре белән, аннан соң – яңалифтә һәм соңгылары кириллицада басылдылар.

А.С.Пушкинның татар теленә тәрҗемә ителгән иҗаты язучылар, әдәбият галимнәре өчен генә түгел, киң катлам укучылар өчен дә кызыклы.

Шагыйрьнең тууына 100 ел тулу уңаеннан 1899 елда Казан университеты каршында А.С.Пушкин истәлегенә Рус телен сөючеләр җәмгыяте оештырыла. Шушы ук елда Казанның Югары Фёдоровка һәм Беренче Театр урамнары Пушкин урамы итеп үзгәртелә. 1956 елда М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры янында А.С.Пушкинга һәйкәл куела (скульпторы Н.К.Вентцель).

2019 елдан Казанда А.С.Пушкин исемендәге Мәдәният үзәге эшләп килә.

## Советуем прочитать: Укырга тәкъдим итәбез:

**Пушкин А.С.** Избранные произведения /вступ. ст. Р.Файзуллина «На свете Пушкин есть!» = Сайланма әсәрләр / Р.Фәйзуллинның «Дөньяда Пушкин бар» дигән кереш мәкаләсе б-н. – Казань: Магариф-Вакыт, 2013. – 390 с.: ил. – Текст на рус. и татар. яз.

**Пушкин А.С.** Лирика А.С.Пушкина в татарских переводах / сост., авт. вступит. ст. Г.Ф.Сафина; науч. ред. Я.Г.Сафиуллин. – Казань: Изд-во филолог. фак-та КГУ, 2005. – 135 с. – на рус. и татар. яз.

**Пушкин А.С.** Сайланма әсәрләр: ике томда. – Казан: Таткнигоиздат, 1954.

Т. 1: Шигырьләр, поэмалар, «Евгений Онегин» романы, әкиятләр, драма әсәрләре. – 1954 .— 742 б.: портр.

Т. 2: Прозаик әсәрләр. – 1954. – 340 б.: портр.б-н.

**Пушкин А.** Сайланма әсәрләр: шигырьләр, поэмалар, әкиятләр / [проект җитәкчесе, китапның төз. һәм кереш сүз авт. Л.М.Шәех]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2019. – 383 б.: рәс., портр. б-н.

Хәтерлим мин гүзәл бер мизгелне...: А.С.Пушкин татар шагыйрьләре тәрҗемәсендә / төз.-ред. **Х.Фәйзрахманова.** – Казан: Мәгариф, 1999. – 139 б.: рәс. – («Мәгариф» нәшрияты к-ханәсе). – Текст парал. рус, татар. тел.

**Воронова Л.Я.,** Сидорова М.М. А.С.Пушкин в Казани (1833–2011): антология материалов: библиогр. указ. – Казань: Отечество, 2013. – 305 с.

**Аюдаг Л.В.** Казанская Пушкиниана: литературно-журналистские, пушкиноведческие исследования. – 2-е изд., испр. и доп. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2004. – 66 с.: ил.

**Пушкин и Казань: казанские коллекции в музеях России: каталог выставки.** – Казань: Фолиант, 2016. – 139 с.: ил., портр., факс.

**Казанский край – поэзии душа: историко-литературный сб.** – Казань: Мир без границ, 2021. – 271 с. – Пушкин Александр Сергеевич. – С. 71–85.

**Девятых Л.** Люди и судьбы. Кн. 1. – Казань: Титул, 2003. – 303 с.: фото. – «Я в Казани с пятого...». – С. 132–146.

**Амиров К.Ф., Ахметзянова Р.Х., Вениаминов Р.Г.** Казанских улиц имена. – Казань: Центр инновационных технологий, 2008. – 589 с. – Улица Пушкина. – С. 400–403.

**Амирханов Р.** Татарская дореволюционная пресса и Пушкин // Магариф. – 1999. – № 6. – С. 46–48.

**Нигматуллин Э.Г.** Восприятие поэзии Пушкина татарскими поэтами // Науч. Татарстан. – 1999. – № 1. – С. 50–55.

**Марданова Л.** Пушкин и Тукай // Воспитание. – 1999. – (Апр. № 4.). – С. 4–5.

**Султанбеков Б.** Пушкин и татарская культура // Респ. Татарстан. – 1999. – 5 июня.

**Колмаков В.** Использование краеведческого материала при изучении повести «Капитанская дочка» // Магариф. – 1999. – № 5. – С. 43–44.

**Фукс А.** Александр Пушкин Казанда // Сөембикә. – 2007. – № 6. – Б. 35.

**Гараева Ф.** Мәңге сүнмәс йолдызлар...: (Тукай һәм Пушкин иҗатларының уртаклыгы) // Фән һәм мәктәп=Наука и школа. – 2000. – № 3. – Б. 108–110.

**Сафиуллин Җ.** А.С.Пушкин иҗатында Коръән // Казан утлары. – 1999. – № 6. – Б. 92–99.

**Нигъмәтуллин Э.** Пушкин һәм татар шагыйрьләре //Мәдәни җомга. – 1999. – 4 июнь. – Б. 15.

**Исламшин Р., Габделхаков В.** Пушкин һәм милли мәдәниятләр // Мирас. – 1999. – № 6. – Б. 61–63.

**Ибраһимов Ш.** Шагыйрь эзләре буйлап // Мәдәни җомга. – 1999. – 4 июнь. – Б. 15.

**Нигъмәтуллин Ә.** Пушкин һәм татар поэзиясе // Ватаным Татарстан. – 1999. – 11 июнь.

**Бөек рус шагыйре** А.С.Пушкинның тууына 200 ел!: мәкаләләр // Ватаным Татарстан. – 1999. – 5 июнь. – Эчт.: Онытма, Пушкин бар / Р.Харис; Бөек сергә ашкыну / Зөлфәт; Пушкинга чәчәк / Роберт Әхмәтҗан.

**Маннап Ш.** Ганнибал оныгы Пушкин татарча белгәнме? // Мәдәни җомга. – 1999. – 4 июнь. – Б. 14.


## 16 июня / июнь



## Хайдар Бигичев
## Хәйдәр Бигичев

**1949–1998**

**75 лет со дня рождения**
**тууына 75 ел**

Певец Хайдар Аббясович Бигичев родился 16 июня 1949 года в деревне Чембилей Краснооктябрьского района Горьковской (ныне Нижегородской) области в многодетной семье. Учился в татарской школе в родной деревне.

Во время службы в рядах Советской Армии Хайдар два года поёт в военном хоре, а по возвращении домой, по совету своего товарища, принимает участие в телевизионном конкурсе «Алло, мы ищем таланты» и побеждает в двух турах.

После участия во Всесоюзном телевизионном конкурсе талантов попал в поле зрения композитора М.Таривердиева, который посоветовал Х.Бигичеву заняться музыкой профессионально.

В 1971 году Х.Бигичев поступает на учёбу в Казанскую консерваторию. В 1977 году, до окончания консерватории, его принимают на работу в Татарский театр оперы и балета имени Мусы Джалиля. Здесь он стал одним из ведущих солистов театра.

Х.Бигичев исполняет главные партии во всех постановках музыкально-сценических произведений татарских композиторов, осуществлённых за период его творческой деятельности: Джик, Джалиль («Алтынчеч», «Джалиль» Н.Жиганова), Самат («Самат» Х.Валиуллина), Закир («Черноликие» Б.Мулюкова), Батыржан («Наёмщик» С.Сайдашева) и др.

Он успешно выступает также в оперных спектаклях классического русского и зарубежного репертуара: Хозе («Кармен» Дж. Бизе), Самозванец («Борис Годунов» М.Мусоргского), Герман («Пиковая дама» П.Чайковского) и др. Вершиной исполнительского мастерства певца стала партия Отелло в одноименной опере Дж.Верди.

Х.Бигичев завоевал широкое признание благодаря своей музыкально-сценической деятельности и выступлениям на концертной эстраде, телевидении и радио. Он является первым исполнителем новых вокальных сочинений композиторов Татарстана, тонким интерпретатором произведений татарского народного песенного творчества. Всесторонне одарённый певец, Х.Бигичев обладал прекрасным голосом неповторимого тембра и широкого диапазона, яркими музыкальными и внешними данными.

Его творчество отличалось высоким профессионализмом и незаурядным художественным воплощением произведений разных жанров и стилей. Исполнительский облик певца характеризовался на редкость гармоничным единством особенностей академического и самобытного, связанного с традициями татарского народного пения, вокала.

В 1970–1990 годы Х.Бигичев – один из наиболее популярных татарских исполнителей, ведёт активную концертную деятельность, выступает с сольными концертами во многих городах России и за рубежом.

Х.А.Бигичеву присвоены почётные звания: в 1980 году народного артиста ТАССР, в 1986 году заслуженного артиста РСФСР. За исполнение роли Са-

мата в опере «Черноликие» Б.Мулюкова в 1984 году ему присуждается Государственная премия Татарстана имени Г.Тукая.

Хайдар Аббясович Бигичев умер 13 ноября 1998 года. Похоронен в Ново-Татарском кладбище города Казани.

В Казани в доме где жил Х.Бигичев (улица Татарстан, дом 7), установлена мемориальная доска в память певца. Именем Х.Бигичева названа улица в Советском районе Казани. В школе № 174 в Казани есть музей певца. 16 июля 2016 года на родине певца – в административном центре Краснооктябрького района – селе Уразовка установлен памятник Х.Бигичеву.

Җырчы Хәйдәр Аббәс улы Бигичев 1949 елның 16 июнендә Горький (хәзерге Түбән Новгород) өлкәсенең Кызыл Октябрь районы Чүмбәли авылында күп балалы гаиләдә туа. Туган авылында татар мәктәбендә укый.

Совет Армиясе сафларында хезмәт иткәндә ике ел хәрби хорда җырлый. Хезмәтен тутырып кайткач, дусты тәкъдиме белән, «Алло, мы ищем таланты» телевизион конкурсында катнашып, ике турда да җиңү яулый. Талантларның Бөтенсоюз телевизион конкурсында жюри әгъзасы, композитор М.Таривердиев Х.Бигичевка игътибар итә һәм ул аңа музыка белән профессиональ рәвештә шөгыльләнергә киңәш итә.

1971 елда Х.Бигичев Казан консерваториясенә укырга керә. 1977 елда аны, консерваторияне тәмамлаганчы ук, Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрына эшкә алалар. Биредә ул әйдәп баручы солистларның берсе була.

Х.Бигичев иҗат эшчәнлеге дәверендә татар композиторларының сәхнәдә куелган барлык музыкаль әсәрләрендә төп партияләрне башкара: Җик Мәргән, Җәлил («Алтынчәч», «Җәлил», Н.Җиһанов), Самат (шул исемдәге опера, Х.Вәлиуллин), Закир («Кара йөзләр», Б.Мулюков), Батырҗан («Наёмщик», С.Сәйдәшев) һ.б. Ул шулай ук рус һәм чит ил классик опера спектакльләрендә Хозе («Кармен», Дж. Бизе), Самозванец («Борис Годунов», М.Мусоргский), Герман («Пиковая дама», П.Чайковский) һ.б. партияләрендә уңышлы чыгышлар ясый. Дж. Вердиның «Отелло» операсындагы Отелло партиясе – җырчының башкару осталыгында иң югары баскыч булып кала.

Җырчы үзенең музыкаль сәхнә эшчәнлеге, концерт эстрадасында, телевидение һәм радиода даими чыгышлары белән киң таныла. Ул Татарстан композиторларының күп яңа вокаль әсәрләрен беренче булып башкара, тамашачыга татар халык җырларының хасиятен үтә сизгер тоемлап тапшыра. Киң диапазонлы, кабатланмас матур тембрлы тавышка, матур буй-сынга ия булган Х.Бигичевның иҗаты югары профессиональлеге, төрле жанрдагы һәм стильдәге әсәрләрне бертигез дәрәҗәдә сәнгатьчә башкару осталыгы белән аерылып тора. Аның башкару манерасына сирәк очрый торган академизм белән халык традицияләренең үзара гармонияле рәвештә кушылуы хас.

Х.Бигичев 1970–1990 елларда иң популяр татар профессиональ башкаручыларының берсе була, актив концерт эшчәнлеге алып бара, Россиянең күп шәһәрләрендә һәм чит илләрдә соло концертлар белән чыгыш ясый.

Хәйдәр Бигичевка 1980 елда ТАССРның халык артисты, 1986 елда РСФСРның атказанган артисты дигән мактаулы исемнәр бирелә, Б.Мулюковның «Кара йөзләр» операсында Закир ролен башкарган өчен 1984 елда Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була.

Хәйдәр Аббәс улы Бигичев 1998 елның 13 ноябрендә вафат була. Кабере Казанда, Яңа бистә зиратында.

Казанда, Х.Бигичев торган йортта (Татарстан урамы, 7) җырчы истәлегенә мемориаль такта урнаштырылган. Казанның Совет районында бер урам Х.Бигичев исемен йөртә. Казанның 174 санлы мәктәбендә җырчының музее бар. 2016 елның 16 июлендә туган ягы Кызыл Октябрь районы үзәге Уразавылда Х.Бигичевка һәйкәл ачылды.

## Советуем прочитать:
## Укырга тәкъдим итәбез:

**Хайдар Бигичев:** воспоминания, интервью, очерки, письма. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2019. – 279 с : фото.

**Народные артисты:** очерки / авт.-сост. И.Илялова. – Казань: Магариф-Вакыт, 2011. – 391 с. – Хайдар Бигичев. – С. 91–95.

**Васильев В.** Воспоминания дирижёра о Хайдаре Бигичеве // Размышления о музыкальном театре

Казанской консерватории: статьи. Воспоминания. Беседы. – Казань: Казан. гос. консерватория, 2010. – С. 43–45.

**Амиров К.Ф.** Казанских улиц имена / К.Ф.Амиров, **Р.Х.Ахметзянова, Р.Г.Вениаминов.** – Казань: Центр инновационных технологий, 2008. – 589 с. – Бигичев Хайдар. – С. 75–76.

**Хәйдәр Бигич**ев: альбом, истәлекләр / төз.: З.Сәхәбиева-Бигичева, Р.Заһидуллина. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. – 327 б. : рәс. + 1 электрон. опт.диск (CD-ROM). – Татар һәм рус телләрендә.

**Сәхәбиева З.** «Үзем исән чакта, Хәйдәр онытылмас»: [әңгәмә] / әңгәмәдәш Г. Гыймадова // Ватаным Татарстан. – 2019. – 19 июль. – Б. 18.

**Хәсәнова А.** Хәйдәр җитми // Ватаным Татарстан. – 2014. – 6 июнь. – Б.18.

**Фәттахов Р.** Хәйдәрләр гасырга бер туа: [әңгәмә] / әңгәмәдәш Г. Гыймадова // Ватаным Татарстан. – 2016. – 12 февраль. – Б.18.

**Миңнуллин Т.** Үз ягының баласы // Безнең мирас. – 2016. – № 7. – Б. 84–85.

**Макаров М.** Җыры калды // Безнең мирас. – 2014. – № 8. – Б. 98–102.

**Ибраһим Х.** «Тыңлар идем тавышыңны...» // Безнең мирас. – 2014. – № 8. – Б. 102–108.

**Арифуллин Ф.** Яратмаска сине мөмкин түгел // Мәдәни җомга. – 2010. – 30 апр. – Б. 18.

## 28 июля / июль



## Якуб Агишев

**1899–1972**

**125 лет**
**со дня рождения**
**тууына 125 ел**

Литературовед, педагог Якуб Халилович Агишев родился 28 июля 1899 года в селе Пенделка Саратовской губернии, ныне Кузнецкого района Пензенской области в семье крестьянина. Начальное образование получает в медресе родной деревни.

В 1915–1918 годах он, при поддержке репетиторов по программе средней школы, экстерном заканчивает Архангельское реальное училище.

В 1919–1925 годах Я.Агишев живёт в Пензе: преподаёт в сёлах Телятине и Кикине, ныне Каменского района; работает уполномоченным губернского отделения народного образования.

В 1926 году приезжает в Казань, в 1930–1933 годах он – студент Казанского педагогического института. Закончив институт и аспирантуру по татарской литературе, Я.Агишев исполняет обязанности заведующего отделом татарского языка и литературы в Институте повышения квалификации кадров народного образования Татарстана (1934–1937), заместителя директора Казанского педагогического училища (1937–1939); затем с октября 1939 до мая 1945 года старшего научного сотрудника, учёного секретаря, заместителя директора в Татарском научно-исследовательском институте языка, литературы и истории. В 1945–1947 годах Якуб Халилович преподаёт в Казанском театральном училище.

В 1946 году Я.Агишев при Учёном совете Восточного института в Москве защитает диссертацию по творчеству Г. Тукая и, получив степень кандидата филологических наук, в 1947–1951 годах работает заведующим кафедрой татарской литературы и доцентом в Казанском государственном педагогическом институте; в 1951–1960 годах преподаёт в Казанском государственном университете.

В печати Я.Агишев начал появляться в период жизни в городе Архангельске. На страницах журнала «Северное жало», «Сабанчы» публикуются многие статьи, очерки, посвящённые вопросам сельского быта, образования, а в тридцатые-пятидесятые годы вместе с другими авторами он работает над составлением программ и учебников-хрестоматий по татарской литературе для средних школ.

В области научных исследований учёный в основном уделяет внимание изучению творчества классиков татарской литературы начала двадцатого столетия, в частности Г. Тукая.

В 1942 году выходит первая книга Я.Агишева «Габдулла Тукай – патриот», а в 1948 и 1954 годах – монографии «Творчество Габдуллы Тукая».

Он также принимает активное участие в состав-

лении двухтомного академического издания произведений Г.Тукая, двухтомного собрания «Избранных произведений», однотомника на русском языке (1958), в написании к ним предисловий и примечаний.

Я. Агишев ещё в 1940 году одним из первых публикует в печати серьёзные статьи, в которых поднимает вопрос о научной периодизации истории татарской литературы.

Якуб Халилович Агишев умер 20 июня 1972 года в Казани.

Әдәбият галиме һәм педагог Якуб Хәлил улы Агишев 1899 елның 28 июлендә элекке Саратов губернасының Кузнецк өязе (хәзерге Пенза өлкәсенең Кузнецк районы) Пәндәлге авылында игенче гаиләсендә туа. Үз авылларындагы мәдрәсәдә укып башлангыч белем алгач, 1915–1918 еллар арасында репетиторлар ярдәме белән урта мәктәп программасы буенча әзерләнеп, экстерн тәртибендә ул Архангельск реаль училищесын тәмамлый.

1919–1925 елларда Я. Агишев туган ягы авылларында балалар укыта. 1926 елда Казанга килә. 1930–1933 елларда ул – Казан педагогия институты студенты. Институтны һәм шунда татар әдәбияты буенча аспирантура тәмамлагач, Я.Агишев Татарстан халык мәгарифе кадрларының белемен күтәрү институтында татар теле һәм әдәбияты бүлеге мөдире (1934–1937), Казан педагогия училищесы директоры урынбасары (1937–1939), аннары 1939 елның октябреннән 1945 елның маена кадәр Татар теле, әдәбияты һәм тарих фәнни-тикшеренү институтында өлкән фәнни хезмәткәр, гыйльми секретарь, директор урынбасары вазифаларын башкара, ә 1945–1947 елларда Казан театр училищесында укыта. 1946 елда Мәскәүдә Көнчыгыш институтының Гыйльми советы каршында Габдулла Тукай иҗаты буенча диссертация яклап, филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә алгач, 1947–1951 елларда Казан дәүләт педагогия институтында татар әдәбияты кафедрасы мөдире һәм доцент булып эшли. 1951–1960 елларда ул Казан дәүләт университетында укыта.

Матбугатта Я.Агишев Архангельск шәһәрендә яшәгән чорында язышa башлый. «Северное жало», «Сабанчы» журналы битләрендә авыл тормышына, мәгариф мәсьәләләренә багышланган күп мәкаләләре, очерк язмалары басыла, ә утызынчы-илленче елларда ул укучылар өчен татар әдәбиятыннан хрестоматияләр төзү һәм дәреслекләр язуда актив катнаша.

Гыйльми тикшеренү өлкәсендә Я.Агишев нигездә егерменче йөз башы татар әдәбияты классиклары, аерым алганда, Г.Тукай иҗатын өйрәнүгә күп көч сала. 1942 елда аның «Тукай – патриот» исемле фәнни-популяр очеркы, 1948 һәм 1954 елларда «Габдулла Тукай иҗаты» («Творчество Габдуллы Тукая») исемле монографияләре дөнья күрә. Ул шулай ук Г.Тукай әсәрләренең ике томлык академик басмасын (1947, 1948), ике томлык «Сайланма әсәрләр» җыелмасын (1954), русча бертомлыгын (1958) төзү, аларга кереш сүз һәм искәрмә-аңлатмалар язу эшендә актив катнаша. Я.Агишев 1940 елда ук беренчеләрдән булып матбугатта татар әдәбияты тарихын фәнни нигездә чорларга бүлү мәсьәләсен күтәргән җитди мәкаләләрен бастыра.

Якуб Агишев 1972 елның 6 июнендә Казанда вафат була.

## Советуем прочитать: Укырга тәкъдим итәбез:

**Агишев Я.** Творчество Габдуллы Тукая: общественно-политические мотивы. – Казань: Таткнигоиздат, 1948. – 94 с.

**Агишев Я.** Творчество Габдуллы Тукая. – 2-е изд., испр. – Казань: Таткнигоиздат, 1954. – 94 с.

**Агишев Я.** Народный поэт Г. Тукай: к 75-летию со дня рождения. – Казан: Татар. кн. изд–во, 1961. – 36 с.

**Агишев Я.** Габдулла Тукай: очерк. – Казан: Татгосиздат, 1946. – 39 б.

**Агишев Я.** Халык шагыйре Г.Тукай. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1961. – 44 б.

**Гиниятуллина А.** Писатели Советского Татарстана: биобиблиогр. спр. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1970. – 511 с. – Агишев Якуб Халилович. – С. 11–12.

**Хусянов Р.** Жизнь, отданная науке и литературе // Респ. Татарстан. – 1999. – 30 нояб.

**Әдипләребез:** биобиблиогр. белешмәлек. 2 том-

да. Т. 1 / [төз. Р.Н.Даутов, Р.Ф.Рахмани]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 751 б. – Якуб Агишев. – Б. 11–12.

**Әдһәмова Г.** Сабак алсын килер буыннар // Ватаным Татарстан. – 1999. – 30 июль.

**Госманов М.** Гыйбрәтле язмышлар: мәгънәле үкенү // Казан утлары. – 2006. – № 7. – Б. 149–166.

## 4 сентября / сентябрь



### Александр Васильевич Вишневский

**1874–1948**

**150 лет со дня рождения**
**тууына 150 ел**

Вишневский вошёл в историю медицины как самобытный учёный-новатор, крупнейший клиницист, выдающийся хирург, создатель оригинальной научной школы. Из 49 лет врачебной и научной деятельности А.В.Вишневского 35 лет отданы Казани.

Именно в Казани он сформировался как врач и учёный, педагог и общественный деятель, здесь им были сделаны главные научные открытия, которые принесли ему мировую известность.

Александр Васильевич Вишневский родился 4 сентября 1874 года в Дагестанском ауле Нижний Чирюрт, в семье штабс-капитана. Среднее образование он получает в Астраханской гимназии, а после её окончания поступает на медицинский факультет Императорского Казанского университета.

После окончания в 1899 году университета, А.В.Вишневский в течение года работает сверхштатным ординатором хирургического отделения городской Александровской больницы Казани. В 1900–1901 годах он – сверхштатный прозектор кафедры оперативной хирургии с топографической анатомией, в 1901–1904 – прозектор кафедры нормальной анатомии. Талантливый молодой специалист в 1903 году защищает докторскую диссертацию, в 1904–1911 годах – приват-доцент кафедры топографической анатомии и оперативной хирургии.

В 1905 году командируется за границу для овладения методами урологических исследований. С 1 апреля 1908 по 15 января 1909 года состоялась его вторая заграничная командировка с целью изучения хирургии мозга и других органов человека; знакомится работой самых лучших клиник Германии, Швейцарии, Франции.

А.В.Вишневский, практически полностью освоив наследие русских и зарубежных анатомических школ, внёс значительный вклад в изучение различных разделов анатомии человека.

В 1910 году А.В.Вишневский начал деятельность консультанта-хирурга в клинике нервных болезней. В 1912 году его избирают заведующим кафедрой хирургической патологии Казанского университета, а с 1916 года молодой профессор стал заведовать кафедрой госпитальной хирургии.

В 1919 году по инициативе А.В.Вишневского, а также других профессоров был основан Институт травматологии; в 1920–1921 годах он также принимает активное участие в организации Института усовершенствования врачей. В суровое время гражданской войны А.В.Вишневский с другими учёными-медиками включился в борьбу с эпидемиями.

Деятельность А.В.Вишневского достигла наивысшего расцвета в период 1923–1934 годов. С 1924 года он регулярно читает студентам курс по урологии. В 1926 году его избирают заведующим кафедрой факультетской хирургии, которой он руководит до отъезда из Казани.

С 1923 по 1934 год А.В.Вишневским было опубликовано около 40 научных работ – экспериментально-физические исследования и многочисленные оригинальные работы по хирургии желчных путей, мочевой системы, грудной полости, нейрохирургии, хирургии военных повреждений и гнойных процессов.

В 1930 году Вишневский предложил оригинальный метод местного обезболивания при операциях по способу ползучего новокаинового инфильтрата, получивший широкое применение в нашей стране и за рубежом.

В 1934 году А.В.Вишневский переезжает в Москву, возглавляет хирургическую клинику Централь-

ного института усовершенствования врачей и Всесоюзного института экспериментальной медицины. Покидая Казань, он оставил здесь многочисленных учеников. Из школы Вишневского вышло 18 профессоров. Одним из лучших учеников стал его сын Александр Александрович.

Осенью 1941 года Вишневский вновь оказался в Казани: сюда была эвакуирована хирургическая клиника. Новые методы обезболивания и лечения ран, предложенные Вишневским, сыграли огромную роль во время Великой Отечественной войны, спасли тысячи советских воинов.

Масляно-бальзамическая повязка («Мазь Вишневского»), предложенная Вишневским в 1927 году, применяется с успехом для лечения ран и сегодня.

А.В.Вишневский был награждён орденами Ленина, Трудового Красного Знамени, медалями, ему присуждалась Государственная премия СССР.

Умер А.В.Вишневский 13 ноября 1948 года в Москве.

В Казани имя известного хирурга увековечено. Одна из центральных улиц города, бывшая Академическая, с 1948 года носит имя Вишневского. В 1936 году его имя присвоено клинике Казанского медицинского университета; рядом с клиникой, носящей его имя, установлен памятник-бюст А.В.Вишневскому (скульптор В.И.Рогожин, архитектор А.А.Спориус).

Вишневский медицина тарихына үзенчәлекле галим-новатор, танылган хирург, оригиналь фәнни мәктәп төзүче буларак кергән. Вишневскийның 49 еллык фәнни һәм табиблык эшчәнлегенең 35 елы Казанда үткән. Монда ул табиб һәм галим, педагог һәм җәмәгать эшлеклесе буларак формалаша, монда үзен бөтен дөньяга танытකан төп фәнни ачышларын ясый.

Александр Васильевич Вишневский 1874 елның 4 сентябрендә Дагъстандагы Түбән Чирюрт авылында, рус гаскәрләре составында хезмәт итүче офицер гаиләсендә туа. Әстерхандагы гимназиядә урта белем алгач, Казан император университетының медицина факультетына укырга керә.

1899 елда университетны тәмамлагач, А.В.Вишневский бер ел Казандагы Александров больницасының хирургия бүлегендә штаттан тыш ординатор булып эшли. 1900–1901 елларда ул – оператив хирургия белән топографик анатомия кафедрасында штаттан тыш прозектор, 1901–1904-тә – нормаль анатомия кафедрасы прозекторы. Сәләтле яшь белгеч 1903 елда докторлык диссертациясен яклый, 1904–1911 елларда – топографик анатомия һәм оператив хирургия кафедрасы приват-доценты була.

1905 елда А.В.Вишневский урологик тикшеренүләр ысулларын өйрәнергә чит илгә командировкага җибәрелә. 1908 елның 1 апреленнән 1909 елның 15 гыйнварына кадәр ул, ми һәм кешенең башка органнары хирургиясен өйрәнү максатыннан, икенче мәртәбә чит илдә командировкада була; Германия, Швейцария, Франциядәге иң яхшы клиникаларның эше белән таныша.

А.В.Вишневский рус һәм чит ил анатомия мәктәпләренең мирасын тулысынча диярлек үзләштереп, кеше анатомиясенең төрле бүлекләрен өйрәнүгә үзеннән зур өлеш кертә.

1910 елның көзендә ул нерв авырулары шифаханәсендә консультант-хирург эшчәнлеген башлый. 1912 елда А.В.Вишневский Казан университетының хирургия патологиясе кафедрасының профессоры итеп сайлана, ә 1916 елдан госпиталь хирургиясе кафедрасын җитәкли башлый.

1919 елда А.В.Вишневский һәм башка профессорлар инициативасы белән Травматология институтына нигез салына; 1920–1921 елларда ул врачларның белемен күтәрү институтын оештыруда актив катнаша. Гражданнар сугышы елларында башка галим-медиклар белән бергәләп эпидемияләргә каршы көрәшә.

1923–1934 елларда А.В.Вишневскийның эшчәнлеге үзенең чәчәк ату чорын кичерә. 1924 елдан ул студентларга даими рәвештә урология курслары укый. 1926 елда аны факультатив хирургия кафедрасының мөдире итеп сайлыйлар, ул кафедра белән Казаннан киткәнче җитәкчелек итә.

1923–1934 елларда А.В.Вишневскийның 40 лап фәнни хезмәте басыла. Ул медицинаның төрле өлкәләренә караган эксперименталь-физик эзләнүләр үткәрә. Вишневский нерв системасының ялкынсыну процессындагы роле турында концепция эшли. Моннан чыгып, ул ялкынсыну процессларын, үлекле яраларны, травма белән бәйле рәвештә барлыкка килгән тетрәнүне (травма шогын) дәвалауның яңа методларын булдыра.

1930 елда Вишневский операция вакытында авыртуны тойдырмау ысулын уйлап таба. Бу үзенчәлекле метод безнең илдә генә түгел, чит илләрдә дә киң кулланыла башлый.

1934 елда А.В.Вишневский Казаннан Мәскәүгә күчә, Врачларның белемен күтәрү үзәк институтының һәм Бөтенсоюз эксперименталь медицина институтының хирургия клиникасына җитәкчелек итә. Казаннан киткәндә ул бирердә күпсанлы шәкертләрен калдыра. Вишневский мәктәбеннән 18 профессор үсеп чыга. Иң яхшы укучыларының берсе – улы Александр Александрович.

1941 елның көзендә, хирургия клиникасы эвакуацияләнү сәбәпле, Вишневский яңадан Казанга кайта. Авыртуларны басуның һәм яраларны дәвалауның Вишневский тәкъдим иткән яңа ысуллары Бөек Ватан сугышы вакытында зур роль уйный, меңләгән совет сугышчысын коткара.

1927 елда Вишневский тәкъдим иткән майлыбәлзәмле бәйләвеч («Вишневский мазе») яраларны дәвалаганда бүген дә уңышлы кулланыла.

А.В.Вишневский Ленин, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр белән бүләкләнә, аңа СССРның Дәүләт премиясе бирелә.

А.В.Вишневский 1948 елның 13 ноябрендә Мәскәүдә вафат була.

Казанда атаклы хирургның исеме мәңгеләштерелгән. Шәһәрнең элеккеге Академическая урамы 1948 елдан Вишневский исемен йөртә. 1936 елда Казан медицина институты клиникасына А.В.Вишневский исеме бирелә; клиника янында А.В.Вишневскийга һәйкәл-бюст куелган (скульпторы В.И.Рогожин, архитекторы А.А.Спориус).

## Укырга тәкъдим итәбез: Советуем прочитать:

**Розенгартен М.Ю., Альбицкий В.Ю.** Страницы из жизни хирурга: А.В.Вишневский в Казани. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1974. – 110 с.

**Захарьян С.Т.** Творческий путь Александра Васильевича Вишневского. – М.: Медицина, 1973. – 102 с.: илл., 1 л. портр.

**Розенгартен М.Ю.** Александр Васильевич Вишневский // Рассказы о казанских ученых. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1983. – С. 166–175.

**Гомазков О.** А.В.Вишневский. Все начиналось в Казани // Мед. газ. – 2001. – 20 апр.

**Трейман В.** Новатор в хирургии // Веч. Казань. – 1984. – 8 сент.

**Харитонов И.Ф.** Роль Александра Васильевича Вишневского в развитии отечественной хирургии // Казан. мед. журнал. – 1975. – № 2. – С. 89–91.

**Шишкин А.И.** А.В.Вишневский // Мед. сестра. – 1975. – № 6. – С. 54–56.

**Амиров К.Ф.** Казанских улиц имена / К.Ф.Амиров, Р.Х.Ахметзянова, Р.Г.Вениаминов. – Казань, 2008. – 592 с. – А.В.Вишневский. – С. 104–106.

**Медведев Н., Сметанин Б.** Бөек хирург хөрмәтенә // Соц. Татарстан. – 1974. – 11 дек.

## 15 сентября / сентябрь



## Габдулла Юсупов
## Габдулла Йосыпов

### 1899–1969

### 125 лет со дня рождения
### туына 125 ел

Драматический актёр, режиссёр, педагог Габдулла Фатхуллович Юсупов родился 15 (27) сентября 1899 года в деревне Бурили Верхнеуральского уезда Оренбургской губернии. В 1919 году окончил Верхнеуральскую гимназию.

Закончив в 1929 году театральное отделение Казанского художественно-театрального техникума, Г.Юсупов в 1930–1932 годах работает актёром и режиссёром Московского центрального татарского рабочего театра, в 1932–1935 годах режиссёром Ленинградского татарского театра, в 1935–1938 годах – Астраханского татарского театра.

Габдулла Юсупов – участник Великой Отечественной войны. В 1946 году он приезжает в Казань и назначается главным режиссёром Республиканского передвижного театра (ныне Театр драмы и

комедии имени К.Тинчурина). Назначение опытного, образованного человека положительно влияет на творческое развитие коллектива. В конце 1940-х годов труппа отличалась разнообразием репертуара.

На сцене театра он поставил ряд спектаклей: «Яшьләр алдатмыйлар» («Неподдающиеся», 1946) М.Файзи, "Тормыш җыры» («Песня жизни») М.Амира, «Күңел дәфтәре» («Дневник») Г.Насыри, «В степях Украины» А.Е.Корнейчука (все – в 1947 году) и другие.

В 1948–1963 годах Г.Ф.Юсупов режиссёр (до 1951 года главный режиссёр) Татарского государственного академического театра им. Г.Камала, на сцене которого поставил свыше 30 спектаклей.

Как сторонник реалистического направления основное внимание уделял педагогической работе с актёрами, подробно анализировал логику действий каждого персонажа, стремился к разнообразию репертуара.

Наряду с такими произведениями современных татарских драматургов, как «Чын мәхәббәт» («Настоящая любовь», 1948), «Бишбуляк» (1949), «Данлы көннәр» («Славные дни», 1953) Т.Гиззата, «Әбли авылы» («Деревня Абли», 1949) Ф.Хусни, «Тын алан шаулый» («Шумит тихая поляна», 1950) С.Кальметова, «Кушнарат» («Неразлучные», 1952), «Кадерле минутлар» («Дорогие минуты», 1953) Г.Насыри, обращался к русской и зарубежной классике – «Он пришёл» (1946) Дж. Б.Пристли), «Бедность не порок» (1949), «Таланты и поклонники» (1956) А.Н.Островского, «Слуга двух господ» (1948) К.Гольдони, «Жорж Данден» (1951) Ж.Б.Мольера.

В период работы в театре Г.Юсупов привлекает и молодых драматургов. Поставленные им пьесы «Профессор кияве» («Зять профессора», 1956) Ш.Хусаинова, «Көзге ачы җилләрдә» («Осенние ветры, 1961) А.Гилязова и др. заняли прочные позиции в национальном репертуаре.

В 1963–1966 годах Г.Юсупов в качестве главного режиссёра руководит Альметьевским татарским драматическим театром. Занимается театральной педагогикой, открывает студию при театре по воспитанию актёров, выпускники которой – К.Валиев, Д.Кузаева, Л.Султанова, Р.Ихсанов, Я.Исмагилов впоследствии становятся ведущими актёрами в театре.

Постановки Г.Юсупова «Габбас Галин» (1963) Ш.Камала, «Ташкыннар» («Потоки», 1964) Т.Гиззата, «Ак калфак» («Белый калфак», 1964) М.Файзи, «Ай тотылган төндә» («В ночь лунного затмения», 1966) М.Карима в значительной степени расширили репертуар театра.

Г.Юсупову присвоено почётное звание заслуженного деятеля искусств Татарской АССР. Он награждён орденом «Знак Почёта», медалями.

Габдулла Юсупов умер 24 октября 1969 года в Альметьевске.

Драма актёры, режиссёр, педагог Габдулла Фәтхулла улы Йосыпов 1899 елның 15 (27) сентябрендә Оренбург губернасы Югары Урал (Верхнеуральск) өязенең Буриле авылында туа. 1919 елда Югары Уралда гимназия тәмамлый.

1929 елда Казан сәнгать-театр техникумының театр бүлеген тәмамлаганнан соң, 1930–1932 елларда ул Мәскәү татар театры режиссёры, 1932–1935 елларда – Ленинград татар агитация театры режиссёры була, 1935–1938 елларда Әстерхан татар театрында эшли.

Габдулла Йосыпов Бөек Ватан сугышында катнаша. 1946 елда ул Казанга кайта һәм Республика күчмә театрының (хәзер К.Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театры) баш режиссёры итеп билгеләнә. Тәҗрибәле, киң белемле кешенең билгеләнүе коллективның иҗади үсешенә уңай йогынты ясый. 1940 нчы еллар ахырында труппа репертуары төрлелеге белән аерыла. Театрда Г.Йосыпов М.Фәйзинең «Яшьләр алдатмыйлар» (1946), М.Әмирнең «Тормыш җыры», Г.Насрыйның «Күңел дәфтәре», А.Корнейчукның «Украина далаларында» (барысы да 1947 елда) һәм башка пьесаларны сәхнәләштерә.

1948–1963 елларда – Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының режиссёры (1951 елга кадәр баш режиссёры) була. Аның сәхнәсендә 30 дан артык спектакль куя.

Сәнгатьтә реалистик юнәлеш тарафдары буларак, Йосыпов пьесаның, һәр образның төгәл логикасын аңлый, әсәрдәге хәрәкәтләрне үтәли күрә. Актерлар белән эшләгәндә Г.Йосыпов әсәрне сәхнәгә куючы гына түгел, алар өчен чын педагог та була.

Ул үз чорының драма әсәрләренә дә, классик һәм тәрҗемә әсәрләргә дә бик еш мөрәҗәгать итә: Т.Гыйззәтнең «Чын мәхәббәт» (1948), «Бишбүләк» (1949), «Данлы көннәр» (1953), Ф.Хөснинең «Әбли авылы» (1949), С.Кальметовның «Тын алан шаулый» (1950), Г.Насрыйның «Кушнарат» (1952), «Кадерле минутлар» (1953), Дж.Б.Пристлиның «Ул килде» (1946), А.Н.Островскийның «Ярлылык гаеп түгел» (1949), «Талантлар һәм аларга баш иючеләр» (1956), К.Гольдониның «Ике хуҗаның хезмәтчесе» (1948), Мольерның «Жорж Данден» (1951) һәм башка әсәрләрне сәхнәләштерә.

Г.Йосыпов эшләгән чорда театрга яшь драматурглар да җәлеп ителә. Ул сәхнәгә куйган әсәрләрдән Ш.Хөсәеновның «Профессор кияве», А.Гыйләҗевның «Көзге ачы җилләрдә» кебек пьесалар театр репертуарында шактый билгеле урын ала.

1963–1966 елларда Г.Йосыпов баш режиссёр сыйфатында Әлмәт татар дәүләт драма театрын җитәкли. Театраль педагогика белән шөгыльләнә, актёрлар тәрбияләү буенча театр каршында студия ача.

Аны киләчәктә театрның нигезен тәшкил итәчәк яшьләр: К.Вәлиев, Д.Кузаева, Л.Солтанова, Р.Ихсанов, Җ.Исмәгыйлев кебек артистлар тәмамлыйлар.

Г.Йосыпов куйган спектакльләр – Ш.Камалның «Габбас Галин»ы (1963), Т.Гыйззәтнең «Ташкыннар»ы (1964), М.Фәйзинең «Ак калфак» (1964), М.Кәримнең «Ай тотылган төндә»се (1966) – театрның репертуарын шактый киңәйтәләр.

Г.Йосыповка 1957 елда Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исем бирелә. Ул «Почёт билгесе» ордены, медальләр белән бүләкләнә.

Г.Йосыпов 1969 елның 24 октябрендә Әлмәт шәһәрендә вафат була.

## Советуем прочитать:
## Укырга тәкъдим итәбез:

**Арсланов М. Г.** Татарское режиссёрское искусство (1941–1956). – Казань, 1997. – 222 с.

**Арсланов М. Г.** Татарское режиссёрское искусство (1957–1990). – Казань: Фикер, 2002. – 272 с.

**Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры.** Йөз ел = Татарский государственный академический театр имени Галиасгара Камала. Сто лет: ике томда: Т.2: альбом. – Казан: Заман: Татар. кит. нәшр., 2009. – 368 б. портр., фоторәс. б-н. – Йосыпов Габдулла Фәтхулла улы. – Б. 80.

**Арсланов М.Г.** Татар театры: энциклопедик сүзлек-белешмә. – Казан: Заман, 2014. – 583 б. – Йосыпов Габдулла Фәтхулла улы. – Б. 289–290.

**Әлмәт татар дәүләт драма театры.** 50 ел / төз. Җ. Рәхимов [һ. б.]. – Әлмәт, 1994. – 136 б. – Г.Йосыпов турында. – Б. 67–74.

**Зәйнашева Г.** Якты эз калды // Мәдәни җомга. – 1999. – 24 сент. – Б. 16.

## 14 октября / октябрь



## Владимир Корчагин

1924–2012

**100 лет со дня рождения**
**тууына 100 ел**

Писатель, известный фантаст советской эпохи, геолог Владимир Владимирович Корчагин родился 14 октября 1924 года в Казани в рабочей семье. С четырнадцати лет начинает работать на заводе (КОМЗ), где проработал до конца.

Без отрыва от производства заканчивает вечернюю среднюю школу, в 1951 году геологический факультет Казанского государственного университета. Учится в аспирантуре, защищает кандидатскую диссертацию.

Получив звание доцента, в течение 36 лет, до 1987 года, успешно занимается научной и преподавательской деятельностью на кафедре минералогии – воспитывает будущих геологов.

Владимир Корчагин много работает со студентами в экспедициях и как следствие хорошо изучает горные богатства нашей страны, особенно Урала и Сибири. Именно там он проникся ощущением

загадочности истории Земли и совершенством красоты природы – обо всём этом ему захотелось рассказать людям.

Героями его книг стали те люди, которые всегда шли с ним по жизни рядом. Этими людьми были студенты, которых он учил, разведчики земных недр, геологи-коллеги.

В 1962 году в Татарском книжном издательстве вышел первый роман писателя – «Тайна реки злых духов», который сразу стал бестселлером 60-х годов XX века.

Он был с восторгом принят не только читателями, благожелательный отзыв автор получил от известного советского фантаста Ивана Ефремова.

Вслед за этой книгой изданы романы «Путь к перевалу» (1968), «Астийский эдельвейс» (1982), «Конец легенды» (1984), «Именем человечества» (1989), «Узники страха» (1991), «Женщина в чёрном» (2002), «Две жизни» (2004) и др.

С 1987 года В.Корчагин – писатель-профессионал.

В 1988 году Владимир Владимирович в Союзе писателей Татарстана становится руководителем его русской секции, а с 2003 года – литературным консультантом.

В 2000 году Владимиру Корчагину присвоено почётное звание заслуженного работника культуры Республики Татарстан.

Он награждён медалями «За доблестный труд в годы Великой Отечественной войны», «Ветеран труда», «Золотая медаль ВДНХ».

В 2000 году за книгу «Подкидыш» он стал первым лауреатом литературной премии Союза писателей Татарстана им. Г.Державина.

Владимир Владимирович Корчагин умер 26 декабря 2012 года в Казани.

Язучы, совет чорының танылган фантасты, геолог Владимир Владимирович Корчагин 1924 елның 14 октябрендә Казанда эшче гаиләсендә туа. Ундүрт яшеннән заводта (КОМЗ) хезмәт юлын башлап җибәрә, сугыш беткәнче эшли. Эштән аерылмыйча кичке урта мәктәпне, 1951 елда Казан дәүләт университетының геология факультетын тәмамлый. Аннары аспирантурада укый, кандидатлык диссертациясе яклый. Доцент исемен алып, 36 ел дәвамында, 1987 елга кадәр, минералогия кафедрасында фәнни һәм уку-укыту эшчәнлеге белән уңышлы шөгыльләнә, булачак геологларны тәрбияли.

Владимир Корчагин студентлар белән экспедицияләрдә күп эшли һәм нәтиҗәдә илебезнең, бигрәк тә Урал һәм Себернең тау байлыкларын яхшы өйрәнә. Нәкъ шул вакытта ул җир тарихының серлелеген һәм табигать матурлыгының камиллеген күңеле белән тойган һәм бу хакта ул кешеләргә сөйләргә теләгән. Аның китапларының геройлары һәрвакыт, гомер буе янәшәсендә йөргән кешеләр була. Алар – ул өйрәткән студентлар, җир асты байлыклары разведчиклары, геолог-хезмәттәшләре.

1962 елда Татар китап нәшриятында язучының беренче романы «Явыз рухлар елгасы сере» («Тайна реки злых духов») басылып чыга һәм шунда ук XX гасырның 60нчы еллары бестселлерына әйләнә. Ул укучылар тарафыннан гына түгел, ә танылган совет фантасты Иван Ефремов тарафыннан да уңай бәяләнә.

Аннан соң бер-бер артлы «Тау сырты аша юл» («Путь к перевалу», 1968), «Астий эдельвейсы» («Астийский эдельвейс», 1982), «Легенданың ахыры» («Конец легенды», 1984), «Кешелек исеме белән» («Именем человечества», 1989), «Курку тоткыннары» («Узники страха», 1991), «Карадан киенгән хатын» («Женщина в чёрном», 2002), «Ике тормыш» («Две жизни», 2004) һ.б. китаплары дөнья күрә.

1987 елдан В.Корчагин – профессиональ язучы.

1988 елдан Владимир Владимирович Татарстан Язучылар берлегендә – башта рус әдәбияты секциясе җитәкчесе, ә 2003 елдан – әдәби консультанты була.

2000 елда Владимир Корчагинга Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исем бирелә. Ул «Бөек Ватан сугышы елларында фидакяр хезмәте өчен», «ВДНХның алтын медале», «Хезмәт ветераны» медальләре белән бүләкләнә.

2000 елда язучы «Ташландык бала» («Подкидыш») китабы өчен Татарстан Язучылар берлегенең Г.Державин исемендәге премиясенең беренче лауреаты була.

Владимир Владимирович Корчагин 2012 елның 26 декабрендә Казанда вафат була.

### Советуем прочитать:
### Укырга тәкъдим итәбез:

**Корчагин В.** Тайна реки злых духов: поэма о минералах. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1963. – 222 с.

**Корчагин В.** Путь к перевалу: роман. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1968. – 408 с.

**Корчагин В.** Конец легенды: научно-фантаст. повесть. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1984. – 223 с.

**Корчагин В.** Именем человечества: научно-фантаст. роман. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1989. – 288 с.

**Корчагин В.** Узники страха: научно-фантаст. роман. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1991. – 224 с.

**Корчагин В.** Астийский эдельвейс: научно-фантаст. роман – Казань: Татар. кн. изд-во, 1994. – 384 с.

**Корчагин В.В.** Подкидыш: повесть. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1998. – 175 с.

**Корчагин В.** Женщина в чёрном: научно-фантаст. роман-детектив. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2002. – 256 с.

**Корчагин В.** Две жизни: повести. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2011. – 159 с.

**Корчагин В.** Творение добра и красоты: [Моя родословная] // Казань. – 2000. – № 9. – С.8–23.

**Корчагин В.** Тормыштан калышмыйча: Татарстан язучыларының XII съездында урыс әдәбияты буенча доклады // Казан утлары. – 1994. – № 8. – Б. 173.

**Гиниятуллина А.** Писатели Советского Татарстана: биобиблиогр. спр. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1970. – 511 с. – Корчагин Владимир Владимирович. – С. 258.

**Галимуллина А.Ф.** Дом и душа: размышления о творчестве казанских писателей. – Казань: Школа, 2008. – 95 с. – Синтез научного и художественного в прозе В.В.Корчагина. – С. 69–75.

**Зайнуллина Г.** Владимир Корчагин: фантаст в эпоху перемен. // Идель. – 2019. – № 10. – С. 64–68.

**Газизова Л.** Мэтр казанской фантастики // Республика Татарстан. – 2004. – 15 окт.

**Гыйләҗева Л.** Геолог – әдәбият хадиме // Мәдәни җомга. – 2004. – 22 окт.

**Илгизәр Г.** Владимир Корчагин серләре // Шәһри Казан. –1999. – 26 нояб.

## 29 декабря / декабрь



### Наки Исанбет
### Нәкый Исәнбәт

### 1899–1992

### 125 лет со дня рождения
### тууына 125 ел

Классик татарской литературы XX века – поэт, драматург, прозаик, учёный-филолог, фольклорист Наки Исанбет (Наки Сиразиевич Закиров) родился 29 декабря 1899 года (по новому стилю 10 января 1900 года) в деревне Малояз Златоустовского уезда Уфимской губернии (ныне Салаватский район Республики Башкортостан) в семье муллы.

Получив начальное образование в родной деревне, в 1910–1917 годах учился сначала в медресе «Хасания» в Уфе, потом в медресе «Мухаммадия» в Казани. В 1917–1920 годах работал учителем татарского языка и литературы в школах. В 1920 году он поступил в Институт народного образования в городе Уфе, затем продолжил учебу в Харьковском университете. Осенью 1923 года Исанбет вернулся в Уфу и до 1929 года работал в разных учебных заведениях.

Осенью 1929 года он переехал в Казань, преподавал в техникуме искусств и химико-технологическом институте, работал на фабрике «Спартак», в 1938–1939 годах заведующим педагогическим кабинетом в Атнинском районе Татарстана. С 1940 года Н.Исанбет, в качестве писателя-профессионала, занимается только литературной и научной деятельностью.

Литературная деятельность Н.Исанбета началась рано. Еще в 1914 году в детском журнале «Ак юл» были опубликованы его первые стихи.

Первый сборник стихов «Чаң» («Набат») был издан в 1925 году. Некоторые песни на стихи поэта – «Уракчы кыз», «Бормалы су», «Син сазыңны уйнадың», «Илкәем» стали народными. Н.Исанбетом написано более пятнадцати баллад и поэм.

В двадцатые годы прошлого века Н.Исанбет начал писать пьесы и вскоре стал одним из ведущих драматургов. Он написал более тридцати драм, комедий, трагедий: «Амирхан хазрет» (1915), «Хижрат» (1923), «Портфель» (1929), «Миркай и Айсылу» (1936), «Спартак» (1940), «Марьям» (1941), «Гюльзамал» (1943) и другие.

Его драматическая поэма «Туляк» (1939) послужила для композитора Назиба Жиганова основой для создания одноименной оперы, премьера которой состоялась в 1945 году. В новой редакции опера ставилась под названием «Тюляк и Су-Слу» в 1967 году на сцене Татарского государственного театра оперы и балета им. М.Джалиля.

Н.Исанбет – мастер комедии. В 1939 году он по мотивам народных легенд восточного фольклора написал одну из лучших своих произведений – комедию «Хуҗа Насретдин» («Ходжа Насретдин»), которая с десяток лет идёт с большим успехом на татарской театральной сцене. Его такие комедии как «Җирән Чичән белән Карачәч сылу» («Рыжий сказитель и его красавица Карачэч», 1942), «Кырлай егете» («Джигит из Кырлая», 1968), «Хәйләкәр Дәлилә» («Хитрая Далиля, 1978) также написаны на основе народных легенд.

На сценах театров с неизменным успехом шли спектакли на историко-биографические темы: «Мулланур Вахитов» (1946), «Муса Джалиль» (1956). Большой успех выпал на долю сценических произведений на лирико-бытовые темы: «Райхан» (1949) и «Зифа» (1954).

В творчестве Н.Исанбета заметное место занимают произведения для детей. Его книги «Куянкай» («Зайчонок»), «Куян маҗаралары» («Приключения зайца»), «Мыраућан агай хәйләсе» («Хитрость Мураузяна») и др. популярны среди юных читателей.

Перу писателя принадлежат и переводы на татарский язык произведений русской и зарубежной классической литературы: «Полтава», «Каменный гость», «Бахчисарайский фонтан» А.С.Пушкина; «Горе от ума» А.С.Грибоедова; «Гамлет», «Король Лир» В.Шекспира; «Тартюф» Ж.-Б.Мольера.

Широко известен Н.Исанбет как учёный, неутомимый собиратель и вдумчивый исследователь татарского фольклора. На протяжении многих лет он неутомимо трудился в области лингвистики и фольклора.

Им выпущен в свет эпос «Идегей» (1940), а трёхтомник «Татар халык мәкальләре» («Татарские народные пословицы», 1959–1967), «Татар халык табышмаклары» («Татарские народные загадки», 1970) являются его фундаментальными трудами в этой области.

В 1989 году издан «Фразеологический словарь татарского языка» в 2-х томах, содержащий около 50 тысяч фразеологических выражений.

Н.Исанбет – заслуженный деятель искуств ТАССР и РСФСР (1957, 1959). За большие труды в области литературы и искусств награждён орденами Ленина (1970), Трудового Красного Знамени (1970), Дружбы народов (1979). В 1968 году удостоен Государственной премии Татарстана им. Г.Тукая. В 1986 году ему было присуждено почётное звание народного писателя ТАССР.

Н.Исанбет умер 15 сентября 1992 года в Казани.

Одна из улиц в Советском районе города Казани носит имя выдающегося писателя Наки Исанбета.

